8 тиен.

Т-0115315



# РУСЧА-ТАТАРЧА АСТРОНОМИЯ ТЕРМИННАРЫ СҮЗЛЕГЕ



Т-0115315

ПРОВЕРЕНО
2008 г.

# РУСЧА-ТАТАРЧА АСТРОНОМИЯ ТЕРМИННАРЫ СҮЗЛЕГЕ

Төзүчеләре:
*Мәхмүд Галеев, Адлер Тимергалин*

*Татарстан Мәгариф министрлыгы раслады*

НАУЧНАЯ БИБЛИОТЕКА
КФУ
0001086539

ҚАЗАН ТАТАРСТАН ҚИТАП НӘШРИЯТЫ 1974

52(03)(075)
Г18

*1100 чамасы терминны эченә ала*

НАУЧНАЯ БИБЛИОТЕКА
им. Н. И. Лобачевского
КАЗАНСКОГО ГОС. УНИВЕРСИТЕТА

Г $\frac{0266-118}{М132(03)-74}$ Б3—39—73—73

© Татарстан китап нәшрияты, 1974.

## «РУСЧА-ТАТАРЧА АСТРОНОМИЯ ТЕРМИННАРЫ СҮЗЛЕГЕ»НЕҢ ТӨП ПРИНЦИПЛАРЫ ТУРЫНДА

Киң катлау укучыларга — мәктәп укытучыларына һәм укучы балаларга, тәрҗемәчеләргә, журналистларга, шулай ук студентларга тәкъдим ителә торган бу сүзлек астрономиягә караган иң мөһим терминнарны — барысы 1100 чамасы сүзне үз эченә ала һәм аларның күбесенә кыска-кыска аңлатма бирә. Аңлатмалар терминның төп эчтәлегенә, мәгънәсенә генә кагыла, аның этимологиясен, ягъни килеп чыгышын күрсәтүне максат итеп куймый.

Сүзлеккә теркәлгән терминнарның күпчелеге астрономия буенча төрле илләрдә чыккан дәреслекләрдән һәм популяр китаплардан, шулай ук газета-журналлардан, календарьлардан җыеп алынды.

Сүзлекне төзегәндә, «Русча-башкортча һәм башкортча-русча астрономия терминнары» сүзлегеннән дә файдаланылды (Уфа, 1954, төзүчесе В. Сөләйманов).

Аңлатмалар «Большая Советская Энциклопедия» (2 һәм 3 нче басмалар), «Физический энциклопедический словарь» (5 томда, 1960—1966), «Толковый словарь математических терминов» (Мәскәү, 1965), «Космонавтика» («Маленькая энциклопедия», 2 нче басма, Мәскәү, 1970) китапларыннан алынды. Шул ук вакытта русча-татарча һәм татарча-русча сүзлекләрдән һәм кардәш тел сүзлекләреннән дә файдаланылды.

Мәгълүм булганча, хәзерге вакытта астрономия фәне революцион үзгәрешләр кичерә. Аның радиоастрономия һәм эксперименталь астрономия кебек яңа тармаклары аерылып чыкты, Җирнең килеп чыгышы, Галәмнең үсеш-эволюциясе турында яңа теорияләр туды, астробиология кебек катнаш фән көннән-көн ныграк нигезләнә бара. Космонавтиканың үсүе астрономияне алга җибәрү өчен зур этәргеч булды. Җирнең һәм Юпитер планетасының радиацион поясlары, «Кояш җиле», Марс кратерлары ачылды, Венераның һәм Марсның өслек температуралары үлчәнде, атмосфера составы билгеләнде. Ай туфрагы химик яктан ныклап тикшерелә башлады һ. б. Хәтта Җир шарының төгәл формасы ачыклану да эксперименталь астрономиягә бурычлы.

Астрономиянең үсүе белән бергә, бик күп яңа терминнар туды һәм аларның байтагы телләрнең гомуми сүзлек фондына кереп урнашты (пульсарлар, квазарлар, «Кояш җиле», стационар иярчен, орбиталь автомат станция һ. б.).

Татарча астрономия терминнары да шактый эшләнгән. Ләкин астрономия терминнары моңа кадәр эзлекле бер системага салынмаган, атама сүзләр чагыштырылмаган һәм бергә тупланмаган, ягъни таркау хәлдә иде. Шуның аркасында терминнарны дөрес кул-

ланмау очраклары да бар, матбугатта аерым атамаларның төрле вариантлары һәм синонимнары йөри, кайбер очракларда исә тел хәзинәсендә электән булган сүз онытылып, бер дә кирәксезгә ясалма терминнар кулланыла. Хәлбуки, төрки телләрдә, гарәп теле йогынтысында, борынгыдан ук фәнни астрономик терминнар эшләнгән булган. Аларның байтагы, соңыннан интернациональ характер алып, барлык телләрнең терминологик байлыгына әверелгән (мәсәлән, Алголь, Алькор, альмукантарат, Бетельгейзе, зенит, надир һ. б.). Шул ук вакытта җанлы телдә байтак кына йолдызларның һәм йолдызлыкларның үз исемнәре булган (Көянтә — Орион, Иләк — Плеяда, Акбүзат һәм Күкбүзат йолдызлары, Әвернә — Лебедь кебекләр). Төзүчеләр бу атамаларны сүзлеккә теркәргә тырыштылар.

Аерым терминнар кардәш телләрдә башкача алына (мәсәлән, Овен — башкортта Тәкә, Йөкче — Олаучы, Пегас — Тулпар, төркидә Кыз йолдызлыгы — Башак һ. б.). Кирәк табылган хәлләрдә, сүзлектә мондый аерымлыкны чагылдыруга да азмы-күпме игътибар ителде һәм аңлатма өлешендә кайбер йолдызлыкларның гарәпчә исеме теркәлде.

Аерым терминнарны татарча бирүнең шактый кыен очраклары бар. Мәсәлән, **блеск, яркость, светимость** терминнары белән эш шулай тора. Аларны без яктырыш, яктылык (дәрәҗәсе) һәм җетелек дип тәкъдим итәбез. Шул ук вакытта **свечение** — елкылдау, **мерцание** — җемелдәү, **звездная величина** — йолдызча зурлык рәвешендә бирелә.

«Спутник» атамасы астрономик мәгънәдә күптән инде иярчен дип алынган һәм терминлашкан иде. Космик киңлеккә ясалма иярченнәр җибәрелә башлагач, «спутник» бөтен дөнья халыклары өчен аңлаешлы сүзгә әйләнде һәм ул сөйләм теленә кереп үзләште. Шул ук вакытта аерым әдәбиятчыларыбыз, бигрәк тә шагыйрьләр, «ясалма юлдаш» дигән сүзне артык күрәләр, вакытлы матбугатта исә «спутник» сүзе күбрәк очрый.

«Юлдаш» сүзендә тигез хокуклылык мәгънәсе бар. Ә күк җисеме булган «спутник» мөстәкыйль түгел, бәлки буйсынган хәлдәге җисем (халыкара термины — сателлит). Өстәвенә, астрономиядә «попутчик» төшенчәсе дә очрый. Мәсәлән, гигант Юпитер планетасының, бер дистә гадәти иярченнәреннән тыш, «юлдаш»лары да бар. Аларның бер өлеше Юпитердан 60° алда, кайберләре шулкадәр үк артка калып, Кояш тирәсендә әйләнеп йөри. Грек мифологиясеннән алынып, Троялылар дип аталган бу астероидлар иярчен түгел, чөнки алар мөстәкыйль планетоидлар, ягъни аларны Юпитерның юлдашлары дип кенә атарга мөмкин.

«Спутник» сүзе исә, әйткәнебезчә, сөйләм телендә актив кулланыла. Ләкин фәнни әдәбиятта төп термин итеп «иярчен» сүзен калдырырга кирәк (бу сүзлектә «спутник» вариант буларак кына бирелде), чөнки «спутник» сүзе тар мәгънәдә — бездә җибәрелгән ясалма иярчен яки, гомумән, ясалма космик объект мәгънәсендә йөри, ә фәнни термин буларак күпчелек телләрдә сателлит, сателлоид сүзләре яки шуларның калька-тәрҗемәсе терминлашкан.

**«Прилив» һәм «отлив», «приливообразующая сила»** терминнары да кыенлык тудыра. Астрономиядә «прилив» су күтәрелешен генә түгел, гомумән башка күк җисеменең тарту көче тәэсирендә теге яки бу җисем «гәүдә»сендә, мәсәлән Җир кабыгында, барлыкка килгән күтәрелешне, кабарынкылыкны да белдерә. Шуңа күрә сүзлектә **прилив** — су күтәрелеше, күтәрелеш рәвешендә бирелде.



Кайбер очракларда, термин ясау өчен ана теле чаралары җитмәгәндә, башка телләргә, беренче чиратта рус теленә һәм рус теле аша кергән халыкара терминологиягә мөрәҗәгать ителде (**сверхновая** — ультраяңа, **сверхгиганты** — супергигантлар, **Служба Солнца** — Кояшны күзәтү хезмәте, яки патруле, **возмущение** — хәрәкәт бозылу, **пертурбация** һ. б.

Аерым терминнарга вариантлар һәм стилистик синонимнар бирү мәгъкуль күрелде. Телебездә киләчәктә аларның берсе өстенлек алыр дип уйларга нигез бар, ә стилистик синонимнар атама сүзне җөмлә төзелешенә яраклаштыру өчен зарур дип табылды.

Русча синонимнар я ике урында, яисә янәшә (берсе җәя эчендә) теркәлде, мәсәлән:

**Космическая пыль...**
**Пыль межзвездная... к. космическая пыль.**
**Северная Корона (Северный Венец)...**

Кушма (тезмә) терминнар гадәттә ике урында биреп барылды һәм шуларның төп төшенчәгә караганы аңлатма белән тәэмин ителде.

Сүзлектәге байтак кына терминнар мәгънәви яктан бер-берсенә бәйләнгәннәр һәм бер-берсен ачыклый яки тулыландыралар. Күләмнең чикләнгән булуын истә тотып, терминнарның эчтәлеген аңлатуда башка сүзгә юнәлтү (теге яки бу сүзгә кайтару) алымы кулланылды һәм бу очракта азакка **к.** (кара) хәрефе куелды. Мәсәлән:

**Аберрация суточная** тәүлеклек аберрация; **к. аберрация света, 1.**

Терминнең берничә мәгънәсе булганда, җәя эчендәге аңлатмада алар 1, 2, ... дип тамгаланды:

**Оптика** оптика *(1. физиканың яктылык күренешләрен өйрәнә торган бүлеге; 2. астрономик инструментлардагы оптик җиһазлар: линзалар, көзгеләр системасы).*

Татарча терминнар янында синонимнар өтер белән аерылды. Мәгънәви аерымлык төсмерләнгән очракларда исә нокталы өтер куелды:

**Обращение** әйләнү, әйләнеш; әйләнеп йөрү.
**Пегас** Пегас, Тулпар *(йолдызлык исеме).*

Терминнарга бирелгән аңлатмалар һәм искәрмәләр энциклопедик тулылыкны күздә тотмый, алар мәгънәдәге төп моментны ачыклау һәм күзаллауга хезмәт итә. Ләкин аерым аңлатмалар һәм билгеләмәләр шактый тулы һәм җәенке (мәсәлән, «календарь», «координаталар системасы» кебек терминнар).

Үз өлкәсендә беренче тәҗрибә булганга, сүзлекнең лөгатьлеге әлегә астрономияне тулы килеш колачлап бетерми, аерым аңлатмалар берьяклы булып күренергә дә мөмкин. Сүзлектән файдаланучылардан килгән тәнкыйть фикерләрен һәм киңәш-тәкъдимнәрне төзүчеләр тирән рәхмәт белән кабул итәчәкләр һәм сүзлекнең яңа басмасын хәзерләгәндә, аларны һичшиксез искә алачаклар.

Сүзлекне дөньяга чыгарырга булышкан иптәшләргә, рецензентларга, Татарстан Мәгариф министрлыгына һәм нәшриятка рәхмәт белдерүне төзүчеләр үз бурычлары дип саныйлар.

*Төзүчеләр*

# А

**Аберрация (света)** яктылык аберрациясе (*күк гөмбәзендә яктырткычның күренмә торышы үзгәрү, тайпылыш; яктылык тизлегенең чикләнгән булуыннан һәм, 1 — күзәтүченең Җир белән бергә тәүлеклек әйләнүеннән, 2 — Җирнең Кояш тирәли әйләнеп йөрүеннән һәм, 3 — Кояш системасының галәмдә хәрәкәт итүеннән килеп чыга*).

**Аберрация вековая** күп гасырлык аберрация; **к. аберрация света, 3.**

**Аберрация годичная** еллык аберрация; **к. аберрация света, 2.**

**Аберрация объектива** объектив аберрациясе (*оптик пыялаларның идеаль булмаулары аркасында сурәттә килеп чыккан тайпылышлар һәм бозылулар — сферик аберрация, хроматик аберрация һ. б.*).

**Аберрация суточная** тәүлеклек аберрация; **к. аберрация света, 1.**

**Абсолютная звездная величина** йолдызның абсолют зурлыгы (*йолдызны билгеле бер стандарт ераклыкта — 10 парсекта дип уйлаганда аның бирәчәк яктырышы*).

**Абсолютно черное тело** абсолют кара җисем.

**Автоколлимация** автоколлимация (*оптик приборның коллиматорыннан параллель бәйләм булып чыккан нурларның яссы көзгедән кайтарылып кире юнәлештә баруы; төрле оптик коралларда, шул исәптән спектраль приборларда кулланыла*).

**Адаптация (глаза)** күз адаптациясе, күз ияләнү (*яктылыкка карап, күзнең сизгерлеге үзгәрү; яктыга һәм караңгыга адаптация, шулай ук төсләр адаптациясе була*).

**Азимут** азимут (*яктырткычтан горизонтка төшерелгән вертикальнең горизонт белән кисешү ноктасыннан алып көньяк ноктасына кадәр булган дуга*).

**Азимут инструмента** инструмент (ның) азимуты.

**Азимут истинный** чын азимут.

**Азимутальная установка (монтировка)** азимуталь җайланма (*телескопны вертикаль һәм горизонталь күчәрләр тирәсендә азимут һәм биеклек буенча төрлечә юнәлтергә мөмкинлек бирә торган җайланма; бу җайланма телескопны йолдыз артыннан үзе бора*).

**Аквариды** акваридлар (*метеор агышы; ел саен апрель азакларында — май башларында һәм июль азакларында — август башларында була*).

**Аккомодация (глаза)** күз аккомодациясе (төрле ераклыктагы *әйберләрне ачык күрергә җайлашуы*).

**Актинометр** актинометр (*Кояшның туры нурланышын үлчәү приборы*).



**Аламак** Аламак (*Андромеда йолдызлыгында $\gamma$ йолдызы*).

**Алараф** Алараф (*Кыз йолдызлыгында $\beta$ йолдызы*).

**Алголи** алгольләр (*Алголь йолдызына охшаган спектраль куш йолдызлар*).

**Алголь** Алголь (*Персей йолдызлыгындагы $\beta$ хәрефе белән тамгаланган үзгәрешле куш йолдызның исеме*).

**Алидада** алидада (*астрономик инструментларда лимб бүлемнәрен күрсәтә торган борылмалы деталь, линейка*).

**Алиот** Алиот (*Җидегәннең $\varepsilon$ йолдызы*).

**Альбедо** альбедо (*яктылык чыгармый торган җисемнәрнең үзләренә төшкән яктылыкны кайтару сәләте*).

**Альбедо астрономическое** астрономик альбедо.

**Альбедо видимое** күренмә альбедо.

**Альбедо геометрическое** геометрик альбедо.

**Альбедо истинное** чын альбедо.

**Альбирео** Альбирео (*Аккош йолдызлыгының $\beta$ йолдызы*).

**Альгена** Альгена (*Игезәкләр йолдызлыгының $\gamma$ йолдызы*).

**Альгениб** Альгениб (*Пегас йолдызлыгының $\gamma$ йолдызы*).

**Альгиеба** Альгиеба (*Арслан йолдызлыгының $\gamma$ йолдызы*).

**Альдебаран** Альдебаран (*Үгезбозау йолдызлыгындагы сары йолдыз исеме; $\alpha$ хәрефе белән тамгалана*).

**Альдерамин** Альдерамин (*Цефей йолдызлыгының $\alpha$ йолдызы*).

**Алькор** Алькор (*Зур Җидегәннең бишенче зурлыктагы йолдызы; Зур Җидегән чүмеченең сабы очыннан икенче урындагы Мицар йолдызы белән бергә физик куш йолдыз тәшкил итә, ягъни аны үткер күзле кеше генә күрә*).

**„Альмагест" Птолемея** Птолемей „альмагесты" (*безнең эраның 2 нче гасыр урталарында Клавдий Птолемей язган астрономик хезмәтнең исеме*).

**Альмукантарат** альмукантарат (*күк гөмбәзендә горизонтка параллель булган кечкенә түгәрәк*).

**Альтазимут** альтазимут (*күк яктырткычларының азимутын һәм биеклеген үлчәү өчен хезмәт иткән борынгы җайланма*).

**Альрами** Альрами (*Укчы йолдызлыгының $\alpha$ йолдызы*).

**Альтаир** Альтаир (*Каракош йолдызлыгындагы ак төстәге $\alpha$ йолдызының исеме*).

**Альфа Центавра** Центавр альфасы (*Центавр йолдызлыгындагы йолдыз; иң якын йолдызларның берсе исәпләнә*).

**Альфард** Альфард (*Гидра йолдызлыгының $\alpha$ йолдызы*).

**Альциона** Альциона (*Иләк йолдызлыгындагы иң якты йолдыз*).

**Андромеда** Андромеда (*йолдызлык исеме*).

**Андромедиды** андромедидлар (*радианты Андромеда йолдызлыгында урнашкан метеор агышы*).

**Аномалия гравитационная** гравитацион аномалия (*Җир тарту көченең теоретик зурлыгы белән чын зурлыгы арасындагы аерма*).

**Аномалия истинная** чын аномалия (*күк җисеменең эллиптик орбитадагы хәрәкәтендә радиус-вектор белән перицентрга таба юнәлеш арасындагы почмак*).

**Аномалия средняя** уртача аномалия (*эллиптик орбитада перицентрга таба юнәлеш белән җисемнең уртача тизлегенә ия булган уйланма нокта радиус-векторы арасындагы почмак*).

**Аномалия эксцентрическая** эксцентрик аномалия (*астрономик хисаплау эшендә уртача аномалиядән чын аномалиягә күчү өчен ярдәм итә торган зурлык*).

**Антарес** Антарес (*Чаян йолдызлыгындагы кызыл төстәге якты йолдыз исеме; α хәрефе белән тамгалана*).

**Антенна многодипольная** күп дипольле антенна (*күп сандагы дипольләрдән торган радиотелескоп антеннасы*).

**Антенна спиральная** спираль антенна.

**Антенна управляемая** идарә ителә торган антенна, идарәле антенна.

**Антиапекс** антиапекс (*күк гөмбәзендә апекска капма-каршы булган нокта*).

**Апекс** апекс (*күк гөмбәзендә Җирнең хәрәкәте юнәлгән нокта. Кояш системасының хәрәкәт апексы Геркулес йолдызлыгында урнашкан*).

**Апиоид** апиоид (*күчәр тирәсендә әйләнә торган сыек хәлдәге җисемнең тигезләнеш формасы — грушасыман рәвеш*).

**Апоастр** апоастр (*иярчен йолдыз орбитасының төп йолдыздан иң ерак ноктасы*).

**Апогей** апогей (*Айның яки ясалма иярченнәр орбитасының Җирдән иң ерак урнашкан ноктасы*).

**Апоселений** апоселений (*Ай тирәсендә әйләнүче ясалма иярчен орбитасының Айга иң ерак ноктасы*).

**Апоцентр** апоцентр (*күк җисеме тирәли әйләнүче икенче бер җисем орбитасының беренче җисемнән иң ерак булган ноктасы*).

**Аппарат спускаемый** төшерелә торган аппарат (*космик станциядән теге яки бу күк җисемен тикшерү өчен аның өстенә төшерелә торган аппарат*).

**Аппроксимация (аппроксимирование)** аппроксимация (*астрономик хисап эшләрендә бер математик объектларны мәгънәдәш объектлар белән алмаштыру*).

**Аргумент широты** киңлек аргументы (*планетаның орбита чатыннан үлчәнгән озынлыгы*).

**Ариэль** Ариэль (*Уран планетасының иярчене*).

**Арктур** Арктур (*Үгез көтүчесе йолдызлыгындагы сары йолдызның исеме; α* хәрефе белән тамгалана).

**Армиллярная сфера** армилляр сфера (*күк яктырткычларының координаталарын билгеләү өчен кулланылган борынгы инструмент*).

**Ассоциация звездная** йолдызлар ассоциациясе (*билгеле бер спектраль класска яки типка карый торган йолдызлар берләшмәсе*).

**Астероиды** астероидлар (*Марс белән Юпитер планеталарының орбиталары арасында әйләнүче кечкенә планеталар, планетоидлар; аларның саны 1700 чамасы булып, кайберләренә исем бирелгән, ә күбесе каталогларга номер белән теркәлгән*).

**Астигматизм** астигматизм (*оптик приборларда була торган аберрациянең бер төре*).

**Астробиология** астробиология; **к. биология космическая.**

**Астроботаника** астроботаника (*башка күк җисемнәрендәге үсемлекләр дөньясы турындагы фән*).

**Астрограф** астрограф (*күк йөзенең теге яки бу өлкәсен фотога төшерү өчен хезмәт итә торган телескоп*).



**Астродинамика** астродинамика (*күк механикасының ясалма күк җисемнәре хәрәкәтен өйрәнә торган бүлеге*).

**Астрология** астрология (*йолдызларның күктәге торышларына карап, кешенең язмышын алдан әйтү белән шөгыльләнә торган хорафат*).

**Астролябия** астролябия (*астрономиядә киңлек һәм озынлыкларны үлчәү өчен кулланылган борынгы инструмент*).

**Астрометрия** астрометрия (*астрономиянең бер бүлеге: Җирнең әйләнүен, күк җисемнәренең күренмә хәрәкәтен, вакыт үлчәү ысулларын һ. б. өйрәнә*).

**Астрометрия фотографическая** фотографик астрометрия.

**Астронавтика к. космонавтика.**

**Астронегатив** астронегатив (*астрограф ярдәмендә төшерелгән фотонегатив*).

**Астрономическая единица расстояния** ераклыкның астрономик берәмлеге (*Җир орбитасы зур ярымкүчәренең уртача озынлыгы — 150 000 000 км*).

**Астрономический календарь** астрономия календаре, астрономик календарь (*астрономиягә кагылышлы күренешләр һәм аларның даталары турында Астрономия җәмгыятьләре тарафыннан һәвәскәр астрономнар, астрономия укытучылары һәм укучылар өчен ел саен чыгарыла торган календарь*).

**Астрономия** астрономия (*космик җисемнәрнең һәм аларның системаларының, шулай ук бөтен Галәмнең хәрәкәтен, үсеш-эволюциясен өйрәнә торган фән*).

**Астрономия внеатмосферная** атмосферадан тыш астрономия.

**Астрономия геодезическая (полевая)** геодезик астрономия.

**Астрономия звездная** йолдызлар астрономиясе (*йолдызларның, йолдыз системаларының һәм, гомумән, күк җисемнәренең төзелешен һәм үсеш-эволюциясен өйрәнә торган фән*).

**Астрономия метеорная** метеорлар астрономиясе.

**Астрономия мореходная** диңгезчелек астрономиясе.

**Астрономия общая** гомуми астрономия.

**Астрономия практическая** практик астрономия (*астрономиянең бер бүлеге: вакыт үлчәү ысулларын, азимутларны, географик координаталарны астрономик юл белән өйрәнү һ. б. белән шөгыльләнә*).

**Астрономия радиолокационная** радиолокацион астрономия (*нәзек бәйләм рәвешендә радиодулкыннар җибәреп, күк җисемнәренең төзелешен өйрәнә торган фән*).

**Астрономия сферическая** сферик астрономия (*күк сферасындагы яктырткычларның күренмә урыннарын билгеләү мәсьәләләрен чишү өчен ысуллар эшләү һәм дөрес вакытны, географик координаталарны үлчәү мәсьәләләре белән шөгыльләнә*).

**Астрономия теоретическая** теоретик астрономия.

**Астрономия экспериментальная** эксперименталь астрономия.

**Астрономические сумерки к. сумерки.**

**Астрономический знак** астрономик билге, тамга; маяк.

**Астроориентир,** астроориентир, астромаяк.

**Астрофизика** астрофизика (*күк җисемнәренең физик хәлен һәм химик составын тикшерү белән шөгыльләнә торган фән*).

**Астрофотография** астрофотография; астрофоторәсем.

**Астрофотометр** астрофотометр *(күк яктырткычларының яктылык дәрәҗәсен үлчәү приборы).*

**Астрофотометр визуальный** визуаль астрофотометр.

**Астрофотометрия** астрофотометрия *(практик астрофизиканың бер бүлеге; йолдызларның яктырышын үлчәү ысулларын өйрәнә).*

**Атлас Луны** Ай атласы.

**Атмосфера** атмосфера *(күк җисемнәренең күбесен, шул исәптән Җирне, Марсны, Юпитерны һ. б. урап алган газ сурүе).*

**Атмосфера газовая** газ (лар) атмосферасы; **к. атмосфера.**

**Атмосфера Солнца** Кояш атмосферасы.

**Афелий** афелий *(Кояш системасындагы планета һәм башка иярченнәр орбитасының Кояштан иң ерак булган ноктасы).*

**Ахернар** Ахернар (*Эридан йолдызлыгындагы йолдыз исеме;* $\alpha$ *хәрефе белән тамгаланган*).

**Аэродинамическое торможение** аэродинамик тормозлану *(хәрәкәт итүче җисемгә, мәсәлән космик корабльгә, һаваның тоткарлык ясап хәрәкәтне әкренәйтүе).*

**Аэролит** аэролит, „күк ташы" *(таш метеоритларның борынгы исеме).*

## Б

**Базис** базиз *(күк җисемнәренең ераклыгын билгеләгәндә параллактик тайпылыш булдыру өчен сайланган ике нокта арасындагы ераклык).*

**Баллистические измерения** баллистик үлчәү *(ясалма иярчен һәм космик станцияләрнең траекторияләрен үлчәү-хисаплау).*

**Беллатрикс** Беллатрикс *(Орион йолдызлыгындагы* $\gamma$ *йолдызының исеме).*

**Белые карлики к. карлики белые.**

**Белые ночи** ак төннәр *(59,5° тан югарырак киңлекләрдә кичке шәфәкъ белән таң яктысының бергә кушылуы аркасында якты булган төннәр).*

**Бенетнаш** Бенетнаш (Зур Җидегәннең $\eta$ йолдызы).

**Бетельгейзе** Бетельгейзе (*Орион йолдызлыгындагы кызыл төстәге якты йолдыз).*

**Биология космическая** космик биология (*галәмдә тереклек мәсьәләләрен тикшерә торган яңа фән).*

**Близнецы** Игезәкләр *(зодиакаль йолдызлык исеме, гарәпчәсе Җуза).*

**Блеск звезды** йолдызның яктырышы, яктылык дәрәҗәсе (*йолдызның йолдызча зурлыгы белән характерлана торган сыйфат; рус телендә бу термин урынына „яркость" термины да кулланыла).*

**„Ближайшая Центавра" („Проксима Центавра")** Центаврның иң якын йолдызы („Центавр Проксимасы") *(Җир шарына иң якын урнашкан йолдызлардан берсе).*

**Блинк-компаратор** блинк-компаратор *(астронегативларда үзгәрешле йолдызларны, кечкенә планеталарны һәм тиз хәрәкәт итә торган йолдызларны табу өчен билгеләнгән җайланма).*

**„Блуждающие звезды"** „адашкан йолдызлар" *(планеталарның күренмә хәрәкәтләре тәртипсез булганга, борынгы греклар аларны планета, ягъни „адашкан" яки „гизә торган" йолдыз дип атаганнар).*



**Болиды** болидлар *(планетаара бушлыктан килеп, Җир атмосферасы аркылы үткәндә кызып, үзеннән яктылык чыгара торган зур каты җисемнәр. Халык телендә моны күк капусы ачылу дип тә йөртәләр).*

**Болометр** болометр *(нурланыш энергиясен үлчи торган прибор).*

**Болометрическая звездная величина** болометрик йолдызча зурлык; **к. звездная величина болометричекая.**

**Большая Медведица** Зур Җидегән *(йолдызлык исеме; халыкта „Чүмеч йолдыз" дигән исеме дә бар).*

**Большой Пес** Зур Эт *(йолдызлык исеме).*

**Боннское обозрение** Бонн каталогы *(Боннда чыгарылган астрономик белешмә).*

**Бороз (к) а** буразна (*Айдагы тирән ярык).*

## В

**Вариации силы тяжести** авырлык көче үзгәрешләре, авырлык көче вариацияләре.

**Вега** Вега (*Лира йолдызлыгында ак төстәге якты йолдыз;* $\alpha$ *белән тамгаланган).*

**Вековой ход** күпьеллык үзгәреш (*астрономик күренешләрнең озак еллар дәвамында үзгәрүе).*

**„Великая щель"** „Олы ярык" *(Киек Каз юлында караңгы урын).*

**Великое противостояние** иң якын кара-каршы торыш *(Марс белән Җирнең бер-берсенә иң якын килгән вакыты;* 15 — 17 *елга бер тапкыр кабатлана).*

**Величина сжатия планеты** планетаның кысылу зурлыгы, яньчелү дәрәҗәсе *(планетаның экваториаль һәм поляр радиуслары аермасының экваториаль радиуска чагыштырмасы).*

**Венера** Венера *(Кояштан 108 миллион км ераклыкта 2 нче урында әйләнеп йөри торган планета; халыкта аны Зөһрә яки Чулпан дип тә йөртәләр).*

**Вертикал первый** беренче вертикал *(меридиан яссылыгына перпендикуляр булган вертикал, ягъни күк сферасындагы зур түгәрәк; аның горизонт белән кисешү ноктапары көнчыгыш һәм көнбатыш ноктапарын бирә).*

**Вертикальный круг** вертикаль түгәрәк *(күк яктырткычларының зенит ераклыгын билгеләү өчен хезмәт итә торган астрономик инструмент).*

**Верхнее соединение** югарыгы кушылыш; **к. соединение.**

**Верхние планеты** югарыгы планеталар *(орбиталары Җир орбитасыннан тышта урнашкан планеталар: Марс, Юпитер, Сатурн, Уран, Нептун һәм Плутон).*

**Весеннее равноденствие** язгы көн-төн тигезлеге.

**Весна** яз *(астрономиядә төньяк ярымшарда Кояш экватордан төньякка таба авыша башлаган көннән — 21 нче марттан алып, җәйге торгынлык көненә — 22 июньгә кадәр булган вакыт аралыгы; бу — астрономик яз).*

**Весы** Үлчәү *(зодиакаль йолдызлык исеме; гарәпчәсе Мизан).*

**Ветвь гигантов** гигантлар тармагы, гигант йолдызлар тармагы *(диаграммада гигант йолдызлар күп урнашкан өлкә).*

**Вещество дозвездное** йолдыз оешу матдәсе *(совет галиме В. А. Амбарцумян фикеренчә, галактикалар шул үтә тыгыз матдәдән яралган).*

**Вещество межзвездное** йолдызара матдә *(йолдызара галәм киңлегендәге тузан, газ болытлары).*

**Видимая яркость** күренмә яктырыш, визуаль яктырыш.

**Визирная линия** визир сызыгы, төбәү сызыгы *(оптик инструментларны төбәү сызыгы).*

**Витки** тулы әйләнешләр *(ясалма иярченнәрнең күк җисеме тирәли әйләнеп чыгулары).*

**Визуально-двойные звезды к. звезды оптически двойные.**

**Виргиниды** виргинидлар *(метеорлар агышы; март-май айларында күзәтелә; радианты Кыз йолдызлыгында).*

**Внешние планеты** тышкы планеталар *(Юпитер группасы планеталары: Юпитер, Сатурн, Уран, Нептун һәм Плутон).*

**Внутренние планеты** эчке планеталар *(Җир группасы планеталары: Меркурий, Венера, Җир һәм Марс).*

**Водолей** Сукояр ( *зодиакаль йолдызлык исеме; гарәпчәсе Дәлү).*

**Водород нейтральный** нейтраль водород *(космик җисемнәр составының 95% ын тәшкил иткән бер атомлы водород).*

**Возмущение движения** хәрәкәт бозылу, үзгәрү; пертурбация.

**Возмущение спутников** иярченнәрнең хәрәкәте бозылу *(күк җисеме тирәли әйләнеп йөрүче иярченнәрнең бүтән җисемнәр тәэсирендә юлларыннан тайпылуы).*

**Возничий** Йөкче *(йолдызлык исеме; башкортта „Олаучы" булып терминлашкан).*

**Возраст звезды** йолдызның яше.

**Волк** Бүре *(йолдызлык исеме)*

**Волна приливная** (су) күтәрелеш (е) дулкыны; **к. приливы** һәм **отливы.**

**Волокно газово-пылевое** газ-тузан җепселләре *(йолдызара томанлыкларда).*

**Волопас** Үгез көтүчесе *(йолдызлык исеме).*

**Волосы Вероники** Вероника чәче *(йолдызлык исеме).*

**Ворон** Козгын *(йолдызлык исеме).*

**Восток** көнчыгыш *(чын горизонтның күк экваторы белән кисешү нокталарыннан берсе. Көн-төн тигезлеге вакытында Кояш чыга торган нокта).*

**Восточная квадратура** көнчыгыш квадратура *(планетаның Кояштан көнчыгышка таба почмакча 90° ераклыкта торуы).*

**Восточная элонгация** көнчыгыш элонгация *(күк йөзендә планетаның Кояштан көнчыгышка таба иң зур почмакча ераклыгы).*

**Восход** калку, чыгу *(Кояш, Ай һәм башка күк яктырткычларының горизонт өстенә күтәрелүе).*

**Вращение (вокруг оси)** (күчәр тирәсендә) әйләнү; әйләнеш.

**Вращение Галактики** Галактиканың әйләнеше *(безнең Галактиканың үзәге тирәли 250 км/сек тизлек белән 200 миллион еллык* период белән *әйләнеше).*

**Вращение Земли** Җирнең әйләнүе *(күчәр тирәсендә).*

**Вращение неба суточное** күкнең тәүлеклек әйләнеше *(Җир шарының үз күчәре тирәсендә сәгать йөрешенә каршы якка әйләнүе аркасында күкнең сәгать теле уңаена әйләнгәндәй булып күренүе).*



**Времена года** ел вакытлары, ел фасыллары.

**Времяисчисление** вакыт исәбе; календарь.

**Время аберрационное** аберрацион вакыт, аберрация вакыты *(күк яктырткычыннан чыккан яктылыкның Җиргә килеп җитү вакыты).*

**Время гражданское** гражданнарча вакыт *(уртача Кояш вакытына 12 сәгать кушып исәпләнә).*

**Время декретное** декретча вакыт *(СССР Халык Комиссарлары Советының 1930 ел 16 июнь декреты буенча, пояс вакытына караганда бер сәгать алга күчерелгән вакыт исәбе. Татарстанның пояс вакыты Мәскәүнең декретча вакытына туры килә).*

**Время звездное** йолдызча вакыт *(йолдызларның күренмә хәрәкәтләренә таянып исәпләнә торган вакыт).*

**Время местное** җирле вакыт *(төн уртасыннан башлап исәпләнә һәм Кояшның күк йөзендәге торышы белән билгеләнә торган вакыт; төрле меридиандагы урыннар өчен төрлечә була).*

**Время мировое (всемирное)** (бөтен) дөнья вакыты *(нуленче, Гринвич меридианының төн уртасыннан исәпли башланган уртача җирле Кояш вакыты).*

**Время Московское** Мәскәү вакыты *(Мәскәүнең декретча вакыты).*

**Время поясное** пояс вакыты *(Җир шарында җирле вакытларның чиксез күп булуы халыкара элемтәгә комачау иткәнлектән, бөтен дөнья 24 төрле пояска бүленеп, аларның һәркайсына үз пояс вакыты бирелгән).*

**Время солнечное истинное** чын Кояш вакыты *(Кояшның күктәге тәүлеклек күренмә хәрәкәте нигезендә исәпләнә торган вакыт; чын Кояш тәүлеге даими булмаганлыктан,* бу *исәп даими түгел).*

**Время солнечное среднее** уртача Кояш вакыты *(уртача Кояшның кульминациядә булу моментыннан исәпләнә башлаган вакыт; бу исәп даимилеген саклый).*

**Время эфемеридное** эфемерида вакыты *(Җирнең тигезсез әйләнүе аркасында вакыт исәбенең дә тигезсез булуыннан котылу өчен кертелгән „тигез агышлы" вакыт исәпләү системасы).*

**Вселенная** галәм, космос *(материянең үсеш-эволюциясендә форма ягыннан чиксез күп төрле һәм күләм ягыннан чикләнмәгән бөтен материаль дөнья).*

**Всемирное тяготение к. тяготение всемирное** һәм **гравитация.**

**Вспышка новой звезды** яңа йолдыз (ның) кабынуы *(йолдыз яктысының кинәт кенә күп тапкырлар артып китүе).*

**Входной зрачок** керү бәбәге *(телескопның оптик системасына керә торган нурлар бәйләмен чикләүче диафрагманың сурәте).*

**Выведение на орбиту** орбитага чыгару *(ясалма күк җисемнәре турында).*

**Высота полюса над горизонтом (широта)** дөнья полюсының горизонттан биеклеге *(урынның географик киңлегенә туры килә).*

**Высота светила** яктырткычның биеклеге *(күзәтүчедән як-*

*тырткычка юнәлгән туры белән горизонт яссылыгы арасындагы почмак).*

**Высота угловая** почмакча биеклек; **к. высота светила.**

**Высотомер** биеклек үлчәгеч *(прибор).*

**Вытянутость орбиты** орбитаның сузынкылыгы; **к. эксцентриситет.**

**Выходной зрачок телескопа** телескопның чыгу бәбәге *(телескопның оптик системасында керү бәбәгенең сурәте).*

## Г

**Галактика** Галактика *(безнең Кояш системасын да үз эченә алган йолдызлар тупланышы. Җирдән күзәткәндә ул күк гөмбәзендә Киек Каз Юлы рәвешендә күренә).*

**Галактика** галактика *(безнең Галактика кебек бер системага оешкан йолдыз тупланышлары).*

**Галактики гигантские** гигант галактикалар *(абсолют йолдызча зурлыгы — 21 тирәсендә булган үтә зур галактикалар).*

**Галактики-карлики** кәрлә галактикалар *(гигант галактикалардан миллиардларча тапкыр тоныграк галактикалар).*

**Галактики спиральные** *спираль галактикалар (әйләнү яссылыклары буенча өермәсыман булып оешкан галактикалар).*

**Галактики эллиптические** эллиптик галактикалар *(эллипс формасында булып күренә торган галактикалар).*

**Гелиограф** гелиограф *(Кояшны фотога төшерү өчен хезмәт итә торган телескоп).*

**Гелиометр** гелиометр *(1° ка кадәр зурлыктагы почмакларны үлчәү өчен хезмәт итә торган астрономик инструмент).*

**Гелиоскоп** гелиоскоп *(Кояш өслеген визуаль күзәтү өчен билгеләнгән телескоп).*

**Гелиостат** гелиостат *(Кояш нурларын кире кайтарып бергенә юнәлештә җибәрә торган ярдәмче прибор).*

**Гелиотроп** гелиотроп *(триангуляциядә горизонталь почмакларны үлчәү җайланмасы).*

**Гелиофизика** гелиофизика *(астрофизиканың Кояш физикасын өйрәнә торган бүлеге).*

**Гелиоцентрическая теория (гелиоцентризм)** гелиоцентрик теория, гелиоцентризм теориясе *(Җир — Кояш тирәсендә һәм үз күчәре тирәсендә әйләнә торган планета, дигән фәнни караш. Аны бөек поляк галиме Николай Коперник 1543 елны дөнья күргән хезмәтендә бәян иткән).*

**Геминиды** геминидлар *(метеор агышы; радианты Игезәкләр йолдызлыгында урнашкан, декабрьның беренче яртысында күзәтелә).*

**Гемма** Гемма *(Төньяк Таҗ йолдызлыгының α йолдызы; чын яктырышы Кояштан 38 тапкыр артыграк).*

**Геодезические спутники** геодезик иярченнәр *(геодезик үлчәү эшләренә хезмәт итә торган ясалма иярченнәр).*

**Геодезия** геодезия *(Җирнең формасы, зурлыгы һәм гравитацион кыры, шулай ук Җир өстен картага төшерү өчен үлчәү эшләре һ. б. турындагы фән).*

**Геоид** геоид *(Җирнең чынбарлыктагы формасы).*

**Геоцентрическая теория (геоцентризм)** геоцентрик теория, геоцентризм теориясе *(2 нче гасырда Александрия шәһәре галиме Клавдий Птолемей тарафыннан тәкъдим ителгән ялгыш теория; ул теория буенча, галәмнең үзәгенә Җир урнашкан, башка күк җисемнәре аның тирәсендә әйләнә).*

**Геркулес** Геркулес *(йолдызлык исеме).*

**Гиады** Гиадлар *(Үгезбозау йолдызлыгында сирәк йолдыз тупланышы).*

**Гидра** Гидра *(йолдызлык исеме).*

**Гиперион** Гиперион *(Сатурн планетасының иярчене).*

**Гироскоп** гироскоп *(әйләнү күчәре юнәлешен үзгәртә ала торган бик тиз бөтерелүче каты җисем; бөтерчек-гироскоплар төрле астрономик һәм геодезик приборларда кулланыла).*

**Глаз невооруженный** гади күз *(оптик приборларсыз карый торган күз).*

**Глобулы** глобулалар *(кечкенә һәм гадәттән тыш тыгыз булган тузан томанлыклары; йолдыз яралуның икенче баскычы).*

**Глобус небесный (звездный)** йолдызлар глобусы, күк глобусы *(күк сферасында күренә торган йолдызлар сурәтләнгән глобус).*

**Гномон** гномон *(горизонталь мәйданга вертикаль утыртылган таяк, борынгы астрономик җайланма; күләгәсенең юнәлешенә һәм озынлыгына карап, Кояшның азимутын һәм биеклеген билгеләргә мөмкин).*

**Гнутие трубы** трубаның бөгелеше *(телескопның авырлык тәэсиреннән бөгелеп, оптик күчәрләрнең авышуы).*

**Год аномалистический** аномалистик ел *(Җирнең перигелий аша үтүләре арасындагы вакыт).*

**Год астрономический (фиктивный)** астрономик (фиктив) ел *(уртача Кояшның туры күтәрелеше 280° булган моменттан башлап исәпләнә торган ел).*

**Год високосный** кәбисә ел *(Юлий календаре буенча дүрт елга бер мәртәбә 366 тәүлектән килә торган ел).*

**Год драконический** драконик ел *(Кояш Ай орбитасының бер үк чатына әйләнеп кайта торган вакыт аралыгы).*

**Год звездный к. звездный год.**

**Год календарьный** календарь ел.

**Год простой** гади ел *(365 тәүлектән торган ел).*

**Год световой** яктылык елы *(озынлык һәм ераклык берәмлеге; яктылык бер ел эчендә үткән ара).*

**Год сидерический (звездный) к. звездный год.**

**Год тропический** тропик ел *(Кояшның бер-бер артлы килгән язгы көн-төн тигезлеге нокталары арасын үтәр өчен киткән вакыт — 365,2422 уртача Кояш тәүлегенә тигез булган ел).*

**Годичный параллакс к. параллакс годичный.**

**Годограф скорости** тизлек (ләр) годографы *(күк җисеменең тизлек векторларын уртак башлангыч ноктага куеп, очларын тоташтыргач килеп чыккан кәкре сызык).*

**Голова кометы** кометаның башы *(кометаның тыгыз өлеше).*

**Голубь** Күгәрчен *(йолдызлык исеме).*

**Гончие Псы** Ау Этләре *(йолдызлык исеме).*

**Горизонт видимый** күренмә горизонт; офык.

**Горизонт математический (астрономический, истинный)** математик (астрономик, чын) горизонт *(күк сферасы белән горизонталь яссылыкның кисешү сызыгы).*

**Горизонтальная система координат** горизонталь координаталар системасы **к. система координат горизонтальная.**

**Горизонтальная установка (горизонтальный телескоп)** горизонталь телескоп *(оптик күчәре горизонт яссылыгында, гадәттә көньяк-төньяк юнәлешендә, хәрәкәтсез урнаштырылган телескоп).*

**Горизонтальный параллакс к. параллакс горизонтальный.**

**Горизонтальные часы** горизонталь сәгать *(Кояш сәгате).*

**Горка центральная** үзәк тау *(Ай кратерының үзәгендә урнашкан калкулык).*

**Гравиметр** гравиметр *(Җир тарту көче тизләнешен үлчәү приборы).*

**Гравиметрия** гравиметрия *(Җир тарту көчен характерлый торган зурлыкларны үлчәү турындагы фән).*

**Гравитационная постоянная к. постоянная тяготения.**

**Гравитационное поле Земли** Җирнең гравитация кыры, Җир тарту кыры; **к. поле тяготения.**

**Гравитация** гравитация, җисемнәрнең бер-берсенә тартылуы.

**Градусные измерения** градуслы почмакча үлчәү.

**Гражданские сумерки к. сумерки гражданские.**

**Граница перемены дат к. линия изменения даты.**

**Гранулы** гранулалар *(Кояш фотосферасында кызган газ болытлары).*

## Д

**Дальность видимого горизонта** күренмә горизонтның (офыкның) ераклыгы *(күзәтүченең биеклегенә бәйле була).*

**Движение видимое (кажущееся)** күренмә хәрәкәт.

**Движение звезд собственное** йолдызларның үз хәрәкәте *(йолдызларның башка йолдызларга карата почмакча күчүләре).*

**Движение планет петлеобразное** планеталарның элмәксыман хәрәкәт итүе.

**Движение планет попятное** планеталарның кирегә хәрәкәт итүе.

**Движение планет прямое** планеталарның туры хәрәкәт итүе.

**Движение полюсов Земли** Җир полюсларының күчүе (хәрәкәт итүе) *(Җир шары географик полюсларының, механика законнары буенча; Җир өслегендә әйләнеп йөрүләре).*

**Движение Солнца годичное** Кояшның еллык хәрәкәте *(Кояшның күк сферасында күк экваторының төн яки көньягына авышып, күк сферасының тәүлеклек әйләнешенә каршы якка күчә барып, ел дигәндә йолдызларга карата элекке ноктасына килүе).*

**Движение Солнца суточное** Кояшның тәүлеклек хәрәкәте *(Кояшның күк сферасы буенча, андагы җисемнәргә карата сәгать йөреше уңаена хәрәкәт итеп, элекке ноктасына кайтуы);* **к. сутки солнечные.**

**Движение эллиптическое** эллиптик хәрәкәт, эллипс буенча хәрәкәт итү *(мәсәлән, Кояш тирәсендә планеталар).*

**Дева** Кыз *(зодиакаль йолдызлык исеме; төрки телләрдә Башак дип тә йөртелә).*

**Деймос** Деймос *(Марс планетасының кечерәк иярчене).*

**Деление Кассини** Кассини бүленеше *(Сатурн боҗрасында караңгы аралыклар; мондый бүленеш метеорлар зонасына да хас).*



**Дельфин** Дельфин *(йолдызлык исеме).*

**Денеб** Денеб *(Аккош йолдызлыгында ак төстәге α йолдызы).*

**Денеб Кайтос** Денеб Кайтос (Кит йолдызлыгында β йолдызы).

**Денебола** Денебола (Арслан йолдызлыгында β йолдызы).

**День** көн *(Кояш чыкканнан алып батканга кадәр узган вакыт аралыгы, аның дәвамлылыгы географик киңлеккә һәм ел вакытларына карап үзгәрә).*

**День весеннего равноденствия** язгы көн-төн тигезлеге көне.

**День осеннего равноденствия** көзге көн-төн тигезлеге көне.

**День солнцестояния** Кояш торгынлыгы көне *(җәен төш вакытында Кояш иң югары, кышын исә иң түбән була торган көн — 22 нче июнь һәм 22 нче декабрь).*

**Деферент** деферент *(Клавдий Птолемей системасында планета хәрәкәт иткән кече түгәрәк — эпицикл үзәге Җир тирәсендә әйләнеп йөри торган зур түгәрәк).*

**Диаграмма Герцшпрунга — Рессела** Герцшпрунг — Рессел диаграммасы *(йолдызларның яктыртучанлыклары белән аларның температурасы һәм төсләре арасындагы бәйләнешне күрсәткән диаграмма; бу диаграмма төс һәм яктыртучанлык диаграммасы дип тә атала).*

**Диаметр линейный** сызыкча диаметр *(яктырткыч диаметрының абсолют озынлыгы).*

**Диаметр угловой** почмакча диаметр *(яктырткыч диаметрының күренү почмагы).*

**Дивная (Удивительная) Кита** Китның гаҗәп йолдызы; **к. Мира.**

**Диана** Диана *(Сатурн планетасының иярчене).*

**Диполи** дипольләр *(радиотапшыргычка яки алгычка симметрик тоташтырыла торган антенна элементлары).*

**Долгопериодические орбиты** зур (озын) периодлы орбиталар.

**Долгопериодические переменные** зур (озын) периодлы үзгәрешле йолдызлар.

**Долгота восходящего узла** күтәрелмә чат озынлыгы; **к. узел восходящий.**

**Долгота гелиоцентрическая** гелиоцентрик озынлык *(эклиптикада язгы көн-төн тигезлеге ноктасыннан көнчыгышка таба яктырткычның киңлекләр түгәрәгенә кадәр үлчәнгән дуга озынлыгы).*

**Долгота галактическая** галактик озынлык *(галактик координаталар системасында координаталарның берсе).*

**Долгота географическая** географик озынлык *(урынның меридиан яссылыгы белән Пулково яки Гринвич обсерваториясеннән башланган нуленче меридиан яссылыгы арасындагы почмак).*

**Долгота географическая восточная** көнчыгыш географик озынлык *(башлангыч, ягъни нуленче меридиан яссылыгы белән шул яссылыктан көнчыгышта яткан берәр урынның меридиан яссылыгы арасындагы почмак).*

**Долгота географическая западная** көнбатыш географик озынлык *(башлангыч, ягъни нуленче меридиан яссылыгы белән шул яссылыктан көнбатышта яткан берәр урынның меридиан яссылыгы арасындагы почмак).*

**Долгота небесная к. долгота эклиптическая.**

**Долгота перигелия** перигелий озынлыгы *(күк җисеме орбитасының бер элементы).*



Научная библиотека им. Н. И. Лобачевского Казанского гос. университета
Т-0115315

**Долгота эклиптическая** эклиптик озынлык *(эклиптик координаталар системасында бер координата);* **к. координаты эклиптические.**

**Доплера эффект** Доплер эффекты; **к. принцип Доплера.**

**Доплеровский сдвиг частоты** Доплерча ешлык тайпылышы; **к. красное смещение.**

**Дракон** Аждаһа *(йолдызлык исеме).*

**Дракониды** драконидлар *(метеор агышы; октябрь башларында күзәтелә, радианты Аждаһа йолдызлыгында).*

**Дубхе** Дубхе *(Зур Җидегәннең α йолдызы).*

**Дуга сумеречная Венеры** Венераның эңгер-меңгер дугасы *(планета дискында көндезге һәм төнге якларны аерып тора).*

**Дуговая минута** дуга минуты *(почмак үлчәү берәмлеге).*

**Дуговая секунда** дуга секунды *(почмак үлчәү берәмлеге).*

**Дуговой градус** дуга градусы *(почмак үлчәү берәмлеге).*

## Е

**Европа** Европа *(Юпитер планетасының иярчене).*

**Единица астрономическая** астрономик берәмлек; **к. астрономическая единица расстояния.**

**Единорог** Сыңармөгез *(йолдызлык исеме).*

**Ежегодник астрономический** астрономия календаре; астрономик белешмә, елъязма.

## Ж

**Жеребёнок** Колын *(иске карталарда йолдызлык исеме).*

**Жертвенник** Корбан *(йолдызлык исеме).*

**Живописец** Рәссам *(йолдызлык исеме).*

**Жираф** Жираф *(йолдызлык исеме).*

**Журавль** Торна *(йолдызлык исеме).*

## З

**Задача двух тел (о двух телах)** ике җисем мәсьәләсе *(күк механикасында бер-берсенә тартыла торган ике җисемнең хәрәкәт итүе турындагы мәсьәлә).*

**Задача многих тел** күп җисемнәр мәсьәләсе *(бу мәсьәлә гомуми очракта чишелмәгән).*

**Закат (заход) светил** яктырткычларның батуы (баюы) *(Кояш, Ай һәм башка күк яктырткычларының горизонт астына төшүләре).*

**Закон Боде** Боде законы; **к. закон планетных расстояний.**

**Закон Ньютона (закон всемирного тяготения)** Ньютон законы *(галәмдә җисемнәрнең бер-берсенә тартылуы турындагы закон; бу закон буенча, ул көчнең зурлыгы шул җисемнәрнең массаларына туры пропорциональ, ә ара еракларыгы квадратына кире пропорциональ).*



**Закон Стефана** Стефан законы *(бу закон буенча, бер күләм берәмлегенә туры килгән энергия температураның дүртенче дәрәҗәсенә пропорциональ).*

**Закон планетных расстояний** планеталар ераклыгы законы.

**Закон площадей** мәйданнар законы *(Кеплерның икенче законы).*

**Законы Кеплера** Кеплер законнары *(немец галиме Иоганн Кеплерның планеталарның Кояш тирәсендәге хәрәкәте турында өч законы).*

**Залив Зноя (Волнений)** Эссе Култык *(Айда; „култык" термины Ай „диңгез"ләренең материкка кереп торган өлешләре мәгънәсендә йөри).*

**Залив Радуги** Салават күпере култыгы *(Айда).*

**Залив Росы** Чык култыгы *(Айда).*

**Залив срединный** Урта култык *(Айда).*

**Запад** көнбатыш *(горизонтның күк экваторы белән кисешү нокталарыннан берсе; көн-төн тигезлеге вакытында Кояш бата торган нокта).*

**Западная квадратура** көнбатыш квадратура *(планетаның Кояштан көнбатышка таба почмакча 90° ераклыкта торуы).*

**Западная элонгация** көнбатыш элонгация *(күк йөзендә планетаның Кояштан көнбатышка таба иң зур почмакча ераклыгы).*

**Запуск спутника** иярчен җибәрү.

**Заря вечерняя** шәфәкъ *(Кояш баегач, көнбатышта берникадәр вакыт дәвам итә торган яктылык).*

**Заря утренняя** таң (яктысы) *(Кояш чыгар алдыннан күкнең көнчыгыш ягының яктыра башлавы).*

**Затмение** тотылу, тотылыш *(күк җисемнәренең икенче җисем күләгәсенә керүе).*

**Затмение Луны** Ай тотылу *(Кояштан Айга бара торган нурлар юлына Җир шары килеп керү аркасында Айга Кояш яктысы төшә алмау күренеше);* **к. Лунные затмения центральные.**

**Затмение Солнца** Кояш тотылу *(Кояштан Җиргә килә торган нурлар юлына Ай керү аркасында Кояш дискының өлешчә яки тулысынча каплануы).*

**Затмение Солнца кольцеобразное** Кояшның бөҗра сыман тотылуы *(кайбер вакытларда Ай белән Җир арасы бераз ерагаю сәбәпле Ай Кояш дискын тулысынча каплап бетерә алмаганлыктан, Кояшның бөҗра рәвешендә күренү очрагы).*

**Затмение Солнца полное** Кояшның тулы тотылуы *(Кояш тотылганда Айның Кояш дискын тулысынча каплавы).*

**Затмение Солнца частное** Кояшның өлешчә тотылуы *(Кояш тотылганда Ай Кояш дискын каплап бетермәгән очрак).*

**Затменно-двойные звезды** тотылышлы куш йолдызлар *(вакыт-вакыт бер-берсен каплый торган куш йолдызлар).*

**Заяц** Куян *(йолдызлык исеме).*

**Звезда γ Малой Медведицы** Акбүзат *(Кече Җидегәннең Тимерказык белән янәшә күренгән йолдызы. Болгарларда һәм Казан татарларында аны Тимерказык йолдызына бәйләп куелган ак аргамак — Акбүзат дип исемләгәннәр).*

**Звезда ε Малой Медведицы** Күкбүзат *(Кече Җидегәннең Тимерказык йолдызыннан исәпләгәндә өченче йолдызы. Болгарларда*

*һәм Казан татарларында Тимерказык йолдызына Акбузаттан арырак итеп бәйләп куелган күк аргамак мәгънәсендә йөри).*

**Звезда полярная** Тимерказык, Поляр йолдыз *(дөньяның төньяк полюсына якын булган йолдыз; Кече Җидегәннең α йолдызы).*

**Звезда утренняя** Чулпан, Таң йолдызы *(таң алдыннан яки Кояш чыгар алдыннан көнчыгыш якта күренә торган планета — Венера).*

**Звездная величина** йолдызча зурлык *(йолдызларның яктылык дәрәҗәсен характерлый торган төп зурлык. Йолдызча зурлыкны күрсәткән сан бер берәмлеккә артканда яктырыш 2,512 тапкыр кимрәк була).*

**Звездная величина болометрическая** болометрик йолдызча зурлык *(болометр ярдәмендә билгеләнә).*

**Звездная величина нулевая** нуленче йолдызча зурлык *(беренче йолдызча зурлыкка караганда 2,512 тапкыр яктырак булган йолдызча зурлык).*

**Звездная величина отрицательная** тискәре йолдызча зурлык *(нуленче йолдызча зурлыкка караганда да яктырак булган йолдызларны характерлау өчен кулланыла).*

**Звездная величина фотографическая** фотографик йолдызча зурлык *(фотога төшерү юлы белән билгеләнә).*

**Звездные скопления** йолдыз тупланышлары.

**Звездные скопления рассеянные** чәчелгән йолдыз тупланышлары, сирәк йолдыз тупланышлары.

**Звездные скопления шаровые** шарсыман йолдыз тупланышлары.

**Звездный год** йолдызча ел *(Җиргә Кояш тирәли йолдызларга карата тулы бер әйләнеш ясау өчен киткән вакыт).*

**Звездный дождь (звездопад)** йолдыз яңгыры; **к. метеорный поток.**

**Звездный каталог** йолдызлар каталогы *(урыннары билгеле булган йолдызларның исемнәре һәм алар турындагы иң кирәкле мәгълүматлар тупланган каталог).*

**Звездный период** йолдызча период *(Кояш иярченнәренә Кояш тирәсендә йолдызларга карата тулы бер әйләнеш ясау өчен киткән вакыт);* **к. сидерический период обращения Земли.**

**Звездообразование** йолдызлар барлыкка килү, йолдыз ясалу; йолдыз оешу.

**Звезды** йолдызлар *(Кояш системасыннан тыш булган эссе шарсыман яктырткычлар).*

**Звезды белые** ак йолдызлар *(өслек температурасы* 10 000° С *тирәсендә булган ак төстәге эссе йолдызлар).*

**Звезды ближайшие** иң якын йолдызлар.

**Звезды визуально-двойные** куш күренмәле йолдызлар *(телескоптан караганда куш булып күренә торган йолдызлар).*

**Звезды главные** төп йолдызлар *(куш яки кабатлы йолдызларда төп йолдыз).*

**Звезды голубые (голубоватые)** күк йолдызлар *(өслек температурасы* 30 000° С *тирәсендә булган, күгелҗем төстәге бик эссе йолдызлар).*

**Звезды двойные** куш йолдызлар *(бер-берсенә якын булып күренә торган ике йолдыз).*



**Звезды желтые** сары йолдызлар *(өслек температурасы* 3000—6000° *булган, Кояш тибындагы сары йолдызлар).*

**Звезды-карлики** кәрлә йолдызлар *(күләм ягыннан Кояштан күп тапкырлар кечкенәрәк йолдызлар);* **к. карлики белые** һәм **карлики красные.**

**Звезды кратные** кабатлы йолдызлар, катлаулы йолдызлар *(берничә йолдыздан торган төркем).*

**Звезды магнитные** магнитлы йолдызлар *(магнит кырлары бик куәтле булган йолдызлар).*

**Звезды нейтронные** нейтрон йолдызлар *(гадәти йолдызлар кебек атом төшләреннән һәм электроннардан түгел, бәлки нейтроннардан торган йолдызлар).*

**Звезды новоподобные** яңа сыман йолдызлар.

**Звезды новые** яңа йолдызлар; **к. вспышка новой звезды.**

**Звезды оптически-двойные** оптик куш йолдызлар *(система тәшкил итмичә, бер-берсенә якын булып күренә генә торган ике йолдыз).*

**Звезды переменные** үзгәрешле йолдызлар *(яктырышлары теге яки бу сәбәптән үзгәреп тора торган йолдызлар).*

**Звезды полуправильные** ярым тәртипле йолдызлар *(үзгәреше тулысынча периодик булмаган йолдызлар).*

**Звезды правильно-периодические** тәртип белән үзгәрешле йолдызлар *(периодик үзгәрешле йолдызлар).*

**Звезды-сверхгиганты** үтә зур (гигант) йолдызлар.

**Звезды сверхновые** ультраяңа йолдызлар.

**Звезды спектрально-двойные** спектраль-куш йолдызлар *(спектр сызыклары периодик рәвештә икегә аерыла торган йолдызлар, мәсәлән, Алголь йолдызы).*

**Звезды-субгиганты** субгигант йолдызлар, ярымгигант йолдызлар.

**Звезды-субкарлики** ярымкәрлә йолдызлар, субкәрлә йолдызлар.

**Звезды тройные** өчәрле йолдызлар *(өч йолдыздан торган төркем яки система).*

**Звезды физически-двойные** физик куш йолдызлар *(бер-берсенә тартылу көче белән бәйләнгән, берсе икенчесе тирәсендә әйләнә торган йолдызлар системасы).*

**Зеленый луч** яшел нур *(Кояш баткан моментта офык читендә кыска гына вакытка күзәтелә торган яшел яктылык).*

**Земной шар** Җир шары; **к. Земля.**

**Земля** Җир *(Кояштан 150 миллион километр ераклыкта әйләнеп йөри торган планета; зурлыгы һәм физик төзелеше ягыннан эчке планеталарга карый. Иярчене — Ай).*

**Земная ось** Җир(нең) күчәре *(әйләнү күчәре).*

**Земной магнетизм** Җир магнетизмы; **к. магнитное поле Земли.**

**Земной экватор** Җир экваторы *(Җирне төньяк һәм көньяк ярымшарларга бүлә торган зур түгәрәк).*

**Зенит** зенит *(күк гөмбәзенең иң югарыгы ноктасы).*

**Зенит-телескоп** зенит-телескоп *(киңлекләрне билгеләгәндә кулланыла торган күчереп йөртелмәле махсус телескоп).*

**Зенитное расстояние** зенит ераклыгы *(яктырткычның зенит ноктасыннан почмакча ераклыгы).*

**Зима** кыш *(астрономиядә Җирнең төньяк ярымшарында*

*Кояшның экватордан көньяк полюска таба иң ерак авышкан турыдан — 22 нче декабрьдан башлап, экватор турысына килү моментына — 21 нче мартка кадәр булган вакыт аралыгы — бары 89 тәүлек; бу астрономик кыш дип атала).*

**Зеркальный телескоп** көзгеле телескоп, телескоп-рефлектор *(объективы көзгедән гыйбарәт оптик инструмент).*

**Змееносец** Еланлы *(йолдызлык исеме).*

**Змея** Елан *(йолдызлык исеме).*

**Зодиак (зодиакальный круг)** зодиак, зодиак түгәрәге *(Кояшның йолдызлар арасында еллык күренмә юлында урнашкан 12 йолдызлык: Овен, Үгезбозау, Игезәкләр, Кысла, Арслан, Кыз, Үлчәү, Чаян, Укчы, Кәҗәмөгез, Сукояр, Балыклар).*

**Зодиакальные знаки** зодиак тамгалары *(зодиакаль йолдызлыкларны билгеләгән махсус шартлы тамгалар).*

**Зодиакальные созвездия к. зодиак.**

**Зодиакальный свет** зодиак яктысы *(Кояш баеганнан соң көнбатышта зодиак өлкәсендә күренә торган аксыл яктылык; Кояш яктысының эклиптика яссылыгында урнашкан сирәк газ-тузан болытында чәчелүечнән килеп чыгы).*

**Золотая Рыба** Алтын Балык *(йолдызлык исеме).*

**Зрительная (подзорная) труба** якынайткыч труба; телескоп.

## И

**Избыток сферический** сферик артыклык *(триангуляциядә сферик өчпочмакның почмаклар суммасы белән гадәти яссы өчпочмак почмаклары суммасы арасындагы аерма).*

**Избыток цвета** төс артыклыгы.

**Излучение синхронное** синхрон нурланыш *(Галактиканың магнит кыры тәэсирендә электроннарның тормозлануы нәтиҗәсендә барлыкка килгән радиодулкыннар).*

**Изменчивость широт** киңлекләрнең үзгәрүчәнлеге *(Җир күчәренең күчүе аркасында географик киңлекләрнең үзгәрүе).*

**Измерения угловые** почмак (ча) үлчәүләр; **к. Градусные измерения.**

**Изофаза** — изофаза *(география картасында Кояш тотылуның бердәй фазалары күренгән урыннар аша үтүче сызык).*

**Изохрона** изохрона *(Кояш тотылганда бер үк фазалар күренгән моментларны тоташтыручы сызык).*

**Икар** Икар *(Җиргә шактый якын килүче астероид).*

**Инвар** инвар *(температура үзгәргәндә күләме бик аз үзгәрә торган эретмә; астрономик сәгать маятниклары ясау өчен кулланыла).*

**Индеец** Индеец, Индус *(йолдызлык исеме).*

**Индикатриса лунного света** Ай яктылыгының индикатрисасы *(күрсәткеч графигы).*

**Инструмент астрономический** астрономия инструменты, астрономия коралы, приборы.

**Инструмент угломерный** почмак үлчәү коралы.

**Интенсивность излучения** нурланышның интенсивлыгы *(энергия микъдары).*

**Интерференция света** яктылык интерференциясе *(бердәй периодлы, ләкин төрле фазадагы яктылык дулкыннарының кушылуы нәтиҗәсендә кайбер урыннарда яктылыкның артуы, кайбер урыннарда кимүе).*



**Интерферометр звездный** йолдыз интерферометры *(йолдызларның диаметрларын һәм куш йолдызларның ара ераклыгын үлчәү өчен билгеләнгән интерферометр).*

**Ио** Ио *(Юпитер планетасының иярчене).*

**Ионосфера** ионосфера *(атмосфераның югарыгы өлешендә уңай ионнар һәм электроннардан торган, электр үткәрүчән сирәк һава катлавы).*

**Ирида** Ирида *(зур астероид).*

**Искривление лучей** нурларның кәкрәюе.

**Искривление пространства** пространствоның кәкрәюе *(релятивистик теориядә гаять зур тарту кырында пространстводагы юнәлешләрнең үзгәрүе, бөгелүе).*

**Истинное солнечное время к. время солнечное истинное.**

**Источник света** яктылык чыганагы *(үзеннән яктылык чыгара торган табигый яки ясалма җисемнәр).*

## К

**Кайма тени** күләгә каймасы *(күләгә читендәге томанлы кайма).*

**Календарь** календарь *(вакыт араларын табигатьтә периодик кабатлана торган күренешләргә, нигездә күк җисемнәренең хәрәкәтенә таянып исәпләү системалары).*

**Календарь Григорианский** Григорий календаре *(Рим папасы Григорий исеме белән йөртелә торган календарь; уртача ел Юлий календарена караганда 400 елга 3 тәүлек озынрак итеп алынган. Аны яңа стиль календаре дип тә атыйлар).*

**Календарь новый (всемирный)** яңа календарь *(Юлий һәм Григорий календарьларындагы җитешсезлекләрне бетерү һәм айларның төрле озынлыкта булуына юл куймау өчен тәкъдим ителгән, ләкин хәзергә проектта гына булган календарь).*

**Календарь хиджери** һиҗри календарь *(Мөхәммәт пәйгамбәрнең икенче шәһәргә күчүенә — һиҗрәтенә багышланган һәм кайбер ислам илләрендә кулланыла торган вакыт исәбе. Ул Айның бер-бер артлы килгән ике кульминация нокталары арасындагы вакытны бер ай дип саный һәм шундый 12 айны, ягъни 354 тәүлекне бер ел дип кабул итә).*

**Календарь Юлианский** Юлий календаре *(Рим императоры Юлий Цезарь заманында кертелгән календарь; анда уртача ел 365 тәүлек һәм 6 сәгатькә тигез, 3 елы 365 тәүлектән, бер елы исә 366 тәүлектән дип кабул ителгән. Бу календарьны иске стиль дип тә йөртәләр).*

**Каллисто** Каллисто *(Юпитер планетасының иярчене).*

**Камера Шмидта** Шмидт камерасы *(көзгеле-линзалы телескоп; сферик көзгесенең үзәгендә коррекция пластинкасы бар, ул көзгенең сферик аберрациясен төзәтә).*

**Каналы Марса** Марс каналлары *(Марс планетасы өслегендә гадәттә туры сызык буенча юнәлгән таплар. Аларны кратерлар тезмәсе, ярыклар һ. б. дип уйлыйлар).*

**Канопус** Канопус *(Киль йолдызлыгында урнашкан α йолдызы).*

**Капелла** Капелла *(Йөкче йолдызлыгында урнашкан Кояш тибындагы сары α йолдызы).*

**Карлики белые** ак кәрләләр *(кызыл кәрлә йолдызларга караганда кечерәк һәм тыгызлыгы Җир тыгызлыгына караганда йөз меңнәрчә тапкыр зуррак булган ак төстәге йолдызлар).*

**Карлики красные** кызыл кәрләләр *(гадәттәге йолдызларга караганда күп кечкенә, ак кәрләләрдән шактый зур, массалары Кояшныкыннан уннарча тапкыр азрак, ә радиуслары* 20 *тапкырлар кечкенә булган кызыл төстәге йолдызлар).*

**Карпаты** Карпат таулары *(Айда).*

**Карта неба** күк картасы *(йолдызлар, томанлыклар һәм Киек Каз Юлы төшерелгән проекцион карта).*

**Кассиопея** Кассиопея *(йолдызлык исеме).*

**Кастор** Кастор *(Игезәкләр йолдызлыгында урнашкан ак төстәге α йолдызы).*

**Каталог звезд к. звездный каталог.**

**Квадрант** Квадрант *(йолдызлык исеме).*

**Квадрант стенной** стена квадранты *(күк яктырткычларының биеклеген билгеләү өчен кулланылган борынгы җайланма).*

**Квадрантиды** квадрантидлар *(метеор агышы; ел азагында—ел башында күзәтелә, радианты Квадрант йолдызлыгында урнашкан).*

**Квадратура восточная к. восточная квадратура.**

**Квадратура западная к. западная квадратура.**

**Квазары** квазарлар *(бездән миллиардларча яктылык елы ераклыгында урнашкан, абсолют йолдызча зурлыгы Кояшныкыннан йөз миллиардларча тапкыр артык, ифрат тыгыз һәм кызылга тайпылышлары бик зур булган, интенсив рәвештә радиодулкыннар һәм микрокисәкчекләр таратучы объектлар. Квазарларны квазийолдызлар дип тә атыйлар).*

**Килопарсек** килопарсек *(мең парсекка тигез ераклык берәмлеге).*

**Киль** Киль *(йолдызлык исеме).*

**Кит** Кит *(йолдызлык исеме).*

**Классы спектров звезд** йолдызларның спектраль класслары *(спектрларына карап бүленгән йолдыз төркемнәре: O, B, A, F, G, K, M һәм N төрләре).*

**Козерог** Кәҗәмөгез *(зодиакаль йолдызлык исеме, гарәпчәсе Җәдди).*

**Коллиматор** коллиматор *(спектроскопта параллель нурлар хасил иту җайланмасы; объективтан һәм диафрагмадан, мәсәлән ярыклы экраннан, тора).*

**Колориндекс (показатель цвета)** колориндекс, төс күрсәткече *(күзнең һәм фотопластинканың яктылыкка сизгерлеге арасындагы аерма).*

**Кольцевые горы** боҗрасыман таулар *(Айда).*

**Кольцо Сатурна** Сатурн боҗрасы *(Сатурн планетасы тирәсендә әйләнеп йөри торган вак кисәкләрдән гыйбарәт яссы боҗра).*

**Кольцо солнечное** Кояш боҗрасы *(астрономик җайланма).*

**Колюр равноденствий** көн-төн тигезлеге колюры *(Кояш торгынлыгы колюрына перпендикуляр яссылыкта урнашкан авышлыклар түгәрәге);* **к. колюр солнцестояний.**

**Колюр солнцестояний** Кояш торгынлыклары колюры *(экватор полюсы һәм эклиптика полюсы аша уза торган зур түгәрәк).*

**Кома** кома *(оптик системаларда сурәтне боза торган аберрацияләрнең бер төре).*

**Кометы** кометалар *(баш өлеше тыгыз төштән, койрык ягы төрле газлардан һәм тузаннан торган күк җисеме; халык аны койрыклы йолдыз дип атый).*

**Кометоискатель** кометаэзләгеч *(махсус прибор).*

**Кометы периодические** периодик кометалар *(Җир тирәсенә билгеле бер период белән әйләнеп кайта торган кометалар; алар Кояш тирәли сузынкы эллиптик орбита буенча әйләнеп йөриләр).*

**Компас** Компас *(йолдызлык исеме);* **к. Корабль Арго.**

**„Конская голова“** „Ат башы“ *(караңгы томанлык).*

**Контейнер приборный** прибор контейнеры *(космостан күк җисеменә төшерелүче аппаратның приборлар урнаштырылган өлеше).*

**Конус полной тени** тулы күләгә конусы *(Җир һәм Ай күләгәләре конусы);* **к. полутень.**

**Конфигурации планет** планеталарның конфигурацияләре *(планета, Җир һәм Кояшның бер-берсенә карата үзенчәлекле торышлары: квадратура, элонгация һ. б.).*

**Координаты гелиоцентрические** гелиоцентрик координаталар *(төп яссылыгы итеп эклиптика яссылыгы алынган системадагы координаталар — гелиоцентрик киңлек һәм гелиоцентрик озынлык).*

**Координаты географические** географик координаталар *(Җир шары өстендәге урыннарның торышын билгели торган зурлыклар системасы).*

**Координаты небесные** күк координаталары *(күк сферасындагы яктырткычларның һәм ярдәмче ноктаacross торышын билгели торган зурлыклар системасы).*

**Координаты относительные** чагыштырма координаталар *(материаль ноктаның икенче бер ноктага карата алынган координаталары).*

**Координаты планетоцентрические** планетоцентрик координаталар *(теге яки бу планетаны үзәк, ягъни башлангыч итеп алып төзелгән сферик координаталар).*

**Координаты топоцентрические** топоцентрик координаталар *(күк яктырткычына таба юнәлешне Җир өслегенең теге яки бу ноктасына карата билгели торган координаталар).*

**Координаты экваториальные** экваториаль координаталар *(төп яссылык итеп экватор яссылыгы алынган координаталар).*

**Координаты эклиптические** эклиптик координаталар *(төп яссылык итеп эклиптика яссылыгы алынган турыпочмаклы гелиоцентрик координаталар).*

**Координационно-вычислительный центр** координацион-хисаплау үзәге *(ясалма иярчен һәм космик станцияләр хәрәкәтен исәпләп тору һәм ул хәрәкәтне программа таләбенә яраклаштыру үзәге).*

**Корабль Арго** Арго корабле *(йолдызлык исеме, ләкин хәзер бу исем кулланылмый; көньяк ярымшардагы бу йолдызлык хәзер*

*дүрткә: Киль, Компас, Корма һәм Җилкән йолдызлыкларына бүленгән).*

**Корма** Корма *(йолдызлык исеме; Арго корабле йолдызлыгының бер өлеше).*

**Корона Солнца** Кояш таҗы; **к. солнечная корона.**

**Коронограф** коронограф *(Кояш таҗын фотога төшерү җайланмасы).*

**Короткопериодические кометы** кыска периодлы кометалар *(эллиптик орбиталары сузынкы булмыйча, Кояш тирәсенә еш әйләнеп кайта торган кометалар).*

**Космическая медицина** космик медицина *(космоста очканда организмда килеп чыгарга мөмкин булган үзгәрешләрне һәм авыруларны кисәтү турындагы медицина).*

**Космическая межпланетная станция** планетаара космик станция *(фәнни максатлар белән планетаара киңлеккә җибәрелгән космик корабль).*

**Космическая пыль** космик тузан *(йолдызара галәм киңлегендә, томанлыкларда була торган үтә вак каты кисәкчекләр).*

**Космическая ракета** космик ракета *(теориясе К. Э. Циолковский тарафыннан эшләнгән һәм космоска очу өчен билгеләнгән ракета).*

**Космические лучи** космик нурлар *(космостан килә торган зур энергияле протон, электрон, позитрон һ. б. кисәкчекләр).*

**Космические объекты** космик объектлар *(күк җисемнәре мәгънәсендә кулланыла торган яңа термин).*

**Космический дым** космик төтен *(космик тузанның аеруча вак төре).*

**Космогония** космогония *(күк җисемнәренең килеп чыгуы, үсеш-эволюциясе турындагы мәсьәләләр белән шөгыльләнүче фән).*

**Космогония планетная** планеталар космогониясе; **к. космогония.**

**Космография** космография *(бу термин элементар астрономия мәгънәсендә кулланыла).*

**Космодром** космодром *(ракета, ясалма иярчен һәм космик станцияләр җибәрү өчен билгеләнгән станция).*

**Космология** космология *(барлык галәмнең астрономик закончалыклары турындагы тәгълимат).*

**Космонавт** космонавт *(космоска очучы; кайбер илләрдә астронавт термины кулланыла).*

**Космонавтика** космонавтика *(галәм киңлегенә аппаратларга утырып очу мөмкинлекләрен өйрәнә торган фән. Астронавтика дигән атама да кулланылышта йөри).*

**Космос** космос, галәм; **к. вселенная.**

**Кохаб** Кохаб *(Кече Җидегәннең β йолдызы).*

**Коэффициент поглощения атмосферы** атмосфераның йоту коэффициенты *(атмосфераның яктылык нурларын йотып калу дәрәҗәсе).*

**Коэффициент прозрачности** үтә күренүчәнлек коэффициенты.

**Коэффициент рассеяния** чәчелү коэффициенты *(билгеле бер тирәлектә яктылык нурларының чәчелү дәрәҗәсе).*

**Красное пятно Юпитера** Юпитерның Кызыл табы *(Юпитер планетасы дискында күренә торган гаять зур кызыл тап; аның нәрсә булуы әлегә ачыкланмаган).*

**Красное смещение** кызылга тайпылыш *(ерак космик объектларның спектраль сызыклары кызыл очка таба күчкән була; бу тайпылыш әлеге объектларның гаять зур тизлек белән ерагаю баруларыннан килә дип аңлатыла);* **к. принцип Доплера.**



**Кратеры** кратерлар *(Айда һәм Марста боҗрасыман таулар; аларның күбесе метеоритлар төшеп бәрелүдән килеп чыккан дип уйланыла).*

**Кратеры-колодца** кое-кратерлар *(Айда кечкенә һәм тирән кратерлар).*

**Кратеры полуопустившиеся (полузатопленные)** яртылаш күмелгән кратерлар *(Айда).*

**Кратные звезды к. звезды кратные.**

**Крест** Әвернә, Хач *(йолдызлык исеме).*

**Крест нитей** җепләр әвернәсе *(оптик приборларда сурәтне үтә нәзек җепләр ярдәмендә дүрт квадрантка бүлә торган әвернә).*

**Кривая блеска** яктырыш кәкресе *(үзгәрешле йолдызларның яктырышын күрсәткән график).*

**Кронглас** кронглас *(югары сыйфатлы оптик пыяла).*

**Круг склонений** авышулар түгәрәге *(экваториаль телескопта авышуларны якынча үлчәү түгәрәге).*

**Круг часовой** сәгатьләр түгәрәге *(экваториаль телескопта сәгатьчә почмакларны үлчәү түгәрәге).*

**Круг широт** киңлекләр түгәрәге *(күк сферасында эклиптика полюсы аша уза торган зур түгәрәк).*

**Кульминация** кульминация *(күк сферасының тәүлеклек әйләнеше вакытында яктырткычның күк меридианы аркылы үтүе).*

**Кульминация верхняя** югарыгы кульминация *(яктырткыч күк йөзендә көнчыгыштан көнбатышка таба хәрәкәт иткәндәге кульминация; калыкмый торган яктырткычларның югарыгы кульминациясе дә горизонт астында була).*

**Кульминация нижняя** түбәнге кульминация *(яктырткычның югары кульминациядән үтеп 12 сәгатьтән соң күк меридианын тагы бер кат кисеп үтүе. Батмый торган яктырткычларның, мәсәлән Җидегәннәрнең, түбәнге кульминациясе дә горизонт өстендә була).*

## Л

**Лаборатория космическая** космик лаборатория *(космосны тикшерү өчен планетаара киңлеккә җибәрелгән автомат яки пилотлы станция).*

**Лебедь** Аккош *(йолдызлык исеме).*

**Лев** Арслан *(йолдызлык исеме, гарәпчәсе Әсәд).*

**Леониды** леонидлар *(метеор агышы; ноябрь урталарында күзәтелә, радианты Арслан йолдызлыгында урнашкан).*

**Лето** җәй *(астрономиядә төньяк ярымшарда Кояшның үз хәрәкәтендә төньяк полюска иң якын нокта турысыннан — 22 нче июньнән башлап, экватор турысына килү моментына — 22 нче сентябрьгә кадәр булган вакыт аралыгы, 93,6 тәүлек. Бу астрономик җәй дип атала. Көньяк ярымшарда бу вакытта — кыш ).*

**Летоисчисление** вакыт исәпләү, ел исәбе *(вакытның зур аралыкларын исәпләү системасы. Бу исәп берәр вакыйгадан башланып китә. Мәсәлән, христиан динчеләре ел исәбен Гайса пәйгам-*

*бәрнең „туган“ көненнән, мөселманнар Мөхәммәт пәйгамбәрнең Мәккәдән Мәдинәгә күчкән көненнән башлаганнар).*

**Летоисчисление именами зверей (животный календарь)** елларны җанвар исемнәре белән исәпләү *(борынгы төрки халыкларда еллар 12 җанвар исеме: 1 — тычкан, 2 — сыер, 3 — барс, 4 — куян, 5 — аждаһа, 6 — елан, 7 — елкы, 8 — куй, 9 — маймыл, 10 — тавык, 11 — эт, 12 — дуңгыз исемнәре белән йөртелгән 12 еллык период).*

**Летучая Рыба** Очар Балык *(йолдызлык исеме).*

**Летящая звезда Барнарда** Барнардның очар йолдызы *(Кояш системасына якын ур ашкан, бик тиз хәрәкәт итүче йолдыз; аның Юпитердан 1,5 тапкыр гына зуррак массалы иярчене, ягъни планетасы бар).*

**Летчик-космонавт** очучы-космонавт.

**Либрация Луны** Ай(ның) либрациясе *(Җирдән караганда Айның үз үзәге тирәсендә тирбәнгәндәй булып күренүе).*

**Либрация Луны оптическая** Айның оптик либрациясе *(Ай үз күчәре тирәсендә даими тизлек белән әйләнсә дә, Җир тирәсендә үзгәрешле хәрәкәт иткәнлектән, аның уңга һәм сулга таба 8° ка борылуы, шулай ук Айның әйләнү күчәре Ай орбитасы яссылыгына почмак ясап торганлыктан, югарыга һәм түбәнгә таба 6° лы почмак ясап борылуы аркасында Ай өслегенең төрле якка тирбәнгәндәй булып күренүе. Мондый либрация безгә, Җирдән торып, Ай өслегенең 60% ын күрергә мөмкинлек бирә).*

**Либрация Луны физическая** Айның физик либрациясе *(Айның гәүдәсе Җиргә таба 0,5 км чамасы „кабарып“ торганлыктан, Ай белән Җирнең үзәкләрен тоташтыручы туры сызыкка карата Айның бераз чайкалып торуы. Бу төр либрация XX гасырның 20 нче елларында Казан янындагы Энгельгардт исемендәге обсерваториядә А. А. Яковкин тарафыннан тикшерелгән).*

**Либрация параллактическая (суточная)** параллакс либрациясе, тәүлеклек либрация *(Ай калыкканда һәм баткан вакытларда Җирдән күзәтүчегә Айның (ера) борылган кебек булып күренүе; бу параллакс бер көн дәвамында Айның, даими күренә торган өлешеннән башка, тагы 1% ын күзәтергә мөмкинлек бирә).*

**Лимб** лимб *(1. Үлчәү коралларында градусларга бүленгән түгәрәк; 2. Ай дискының әйләнәсе, чите; көндезге якта якты лимб, төнге якта караңгы лимб дип атала).*

**Линии корональные** таҗ сызыклары *(Кояш таҗы спектрындагы сызыклар).*

**Линия апсид** апсидлар сызыгы *(планеталарның афелий һәм перигелий нокталарын тоташтыручы сызык; ул планета орбитасының зур күчәре була).*

**Линия изменения даты (линия перемены дат)** дата үзгәрү сызыгы *(яңа тәүлек башлану сызыгы; ул Тын океанда Американың көнбатыш, Азия һәм Австралиянең көнчыгыш ярлары арасыннан төньяктан көньякка таба үтә).*

**Лира** Лира *(йолдызлык исеме).*

**Лириды** лиридлар *(метеор агышы; апрельнең икенче яртысында күзәтелә, радианты Лира йолдызлыгында урнашкан).*

**Лисичка** Төлке *(йолдызлык исеме).*

**Локсодромия** локсодромия *(Җир өслегенең Меркатор картасында ике ноктаны тоташтыручы туры сызык; ләкин ул бу ике нокта арасындагы иң кыска юл түгел);* **к. ортодромия.**



**Луна** Ай *(Җир шарыннан уртача 380 мең километр ераклыктагы, үз күчәре тирәсендә 27,3 тәүлектә бер әйләнеш ясый торган табигый иярчен).*

**Лунные затмения центральные** үзәктәш Ай тотылулары *(Ай, Җир һәм Кояш үзәкләре бер туры сызыкта яткан вакыттагы Ай тотылулар; мондый тотылулар аеруча озакка сузыла).*

**Лучевая скорость** нур буенча тизлек *(күк җисеменең Җирдән ерагаю яки Җиргә якынаю тизлеген бирә; күк җисемнәренең тизлек векторының Җир шарын һәм шул яктырткычны тоташтырган туры сызыкка проекциясе).*

**Лучевое равновесие** нурлар тигезләнеше *(Кояш һәм даими йолдызлар эчендә температура арта барып, читкә таралган энергиянең температура градиентына пропорциональ булуы).*

**Лучеиспускание** нур чыгару; радиация.

**Лучи** нурлар *(Ай кратерларыннан таралган якты сызыклар).*

## М

**Магелланово облако большое** Зур Магеллан болыты *(күктәге томанлык исеме);* **к. облака Магеллановы.**

**Магелланово облако малое** Кече Магеллан болыты *(күктәге томанлык исеме);* **к. облака Магеллановы.**

**Магнитное поле Земли** Җирнең магнит кыры *(Җир магнетизмы тәэсирендә Җир тирәсендә барлыкка килгән магнит кыры).*

**Магнитные бури** магнит давыллары *(Җир магнит кыры көчәнешлелегенең, гадәттәге тәүлеклек салмак үзгәреп торуыннан тыш, Кояштагы процессларга бәйле рәвештә, кинәт кенә тәртипсез үзгәреше).*

**Магнитный эффект метеоров** метеорларның магнит эффекты.

**Максимум солнечной деятельности** Кояш эшчәнлегенең максимумы *(таплар күбәйгән чор; 11 елга бер тапкыр кабатлана).*

**Малая Медведица** Кече Җидегән *(йолдызлык исеме).*

**Малая ось** кече күчәр *(күк җисеме орбитасының кечкенә күчәре).*

**Малая планета** кече планета *(астероид).*

**Малый Конь** Кечкенә Ат *(йолдызлык исеме).*

**Малый Лев** Кечкенә Арслан *(йолдызлык исеме).*

**Малый Пес** Кечкенә Эт *(йолдызлык исеме).*

**Маркаб** Маркаб *(Пегас йолдызлыгында α йолдызы).*

**Марс** Марс *(Кояштан уртача 228 миллион километр ераклыкта, Җирдән соң, ягъни дүртенче урында әйләнеп йөри торган, 2 иярченле планета).*

**Масса гравитационная** гравитацион масса *(бөтендөнья тартылу законын сурәтләүче формулага кергән масса).*

**Масса инертная** инерт масса *(җисемгә куелган көчнең тизләнешкә бәйлелеген күрсәткән формулага кергән масса).*

**Маятник конический** конуслы маятник *(тирбәндереп җибәргәндә бер якка таба бераз тизләнеш алу аркасында оваль кәкре сызык сызучы Фуко маятнигы);* **к. маятник Фуко.**

**Маятник оборотный** әйләнмә маятник *(каты штангасының бер очына җиңел йөк, икенче очына авыр йөк беркетелгән һәм*

*ике таяну призмасы булган маятник; һәр ике призмага таянганда да тирбәнү периоды бертигез).*

**Маятник Фуко** Фуко маятнигы *(Җир шарының тәүлеклек әйләнешен исбат итү өчен,* 1851 *елны француз галиме Фуко ясап сынаган озын маятник).*

**Мегапарсек** мегапарсек *(миллион парсек);* **к. парсек.**

**Мегрец** Мегрец *(Зур Җидегәннең* δ *йолдызы).*

**Межзвездная пыль** йолдызара тузан; **к. космическая пыль.**

**Межзвездная среда** йолдызара мохит, йолдызара тирәлек.

**Межзвездное поглощение света** яктылыкның йолдызара тирәлектә йотылуы.

**Межзвездный газ** йолдызара газ.

**Менисковый телескоп** менисклы телескоп *(Максутов телескобы; мениск системасы нигезендә ясалган көзгеле-линзалы телескоп, аның аберрацион кимчелекләре бик аз).*

**Менкар** Менкар *(Кит йолдызлыгында* α *йолдызы).*

**Мерак** Мерак *(Зур Җидегәннең* β *йолдызы).*

**Меридиан географический** географик меридиан *(Җир шары өслегендәге ике полюс һәм географик урын аркылы үткән зур түгәрәк дугасы).*

**Меридиан главный** төп меридиан *(исәп башлана торган нуленче Гринвич меридианы).*

**Меридиан небесный** күк меридианы *(күк сферасының полюслары, зенит һәм надир нокталары аркылы үткән зур түгәрәк).*

**Меркурий** Меркурий *(Кояштан уртача* 58 *миллион километр ераклыкта әйләнеп йөри торган, беренче урындагы планета; иярчене юк).*

**Меропа** Меропа *(Үгезбозау йолдызлыгының* 23 *нче йолдызы).*

**Мерцание** җемелдәү.

**Месяц** ай *(Кояш һәм Ай хәрәкәтләренә нигезләнгән вакыт үлчәү берәмлекләре).*

**Месяц звездный (сидерический)** йолдызча ай *(Айның йолдызларга карата бер тулы әйләнеш ясавы өчен киткән вакыт —* $27^1/_3$ *тәүлек).*

**Месяц сидерический** сидерик ай; **к. месяц звездный.**

**Месяц синодический** синодик ай *(Айның бер-бер артлы килгән бер төрле ике фазасы арасындагы вакыт —* $29^1/_2$ *тәүлек).*

**Месяц солнечный** Кояшча ай *(Кояшча елның, чама белән, уникедән бер өлеше. Ул шартлы рәвештә* 28, 29, 30 *һәм* 31 *тәүлек итеп кабул ителгән).*

**Месяц тропический** тропик ай *(Айның озынлык координатасы* 360° *ка арткан вакыт аралыгы; ул сидерик айдан бераз кыскарак).*

**Метагалактика** метагалактика *(безгә билгеле булган барлык галактикаларны үз эченә алган гаять зур система).*

**Метеор** метеор *(планетаара киңлектән Җир атмосферасына кергәч, кызып якты эз калдыра торган таш һәм тузан кисәкләре. Халык телендә аны „йолдыз атылу“ дип атыйлар).*

**Метеорит** метеорит *(планетаара киңлектән килеп Җиргә төшкән каты күк җисеме).*

**Метеорит железный** тимер метеорит.

**Метеоритика** метеоритика *(метеорларны өйрәнү турындагы фән).*

**Метеоритный кратер** метеорит кратеры *(метеор төшеп бәрелүдән хасил булган чокыр).*

**Метеорный поток** метеор(лар) агышы *(билгеле бер орбита буенча Кояш тирәли әйләнеп йөри торган метеорит җисемнәр; Җир белән очрашканда, „йолдыз яңгыры“ күзәтелә).*

**Метеоритный след** метеорит эзе *(күктә метеорит калдырган эз, юл).*

**Метонов цикл** Метон циклы *(Ай фазалары календарьның бер үк көннәренә туры килә башлавы өчен киткән вакыт* 19 *ел).*

**Механика небесная; к. небесная механика.**

**Механика тел переменной массы** үзгәрмә массалы җисемнәр механикасы *(мәсәлән, ракета хәрәкәте механикасы).*

**Микрометеориты** микрометеоритлар *(үтә вак метеорлар).*

**Микроскоп** Микроскоп *(йолдызлык исеме).*

**Мимас** Мимас *(Сатурн планетасының иярчене).*

**Минута** минут *(почмак һәм вакыт үлчәү берәмлеге).*

**Мир** дөнья *(астрономиядә галәм мәгънәсендә йөри).*

**Мира** Мира, Гаҗәп йолдыз *(Кит йолдызлыгында урнашкан һәм яктырышы бик нык үзгәрүчән йолдыз).*

**Миранда** Миранда *(Уран планетасының иярчене).*

**Мирах** Мирах *(Андромеда йолдызлыгында* β *йолдызы).*

**Мирзам** Мирзам *(Зур Эт йолдызлыгында* β *йолдызы).*

**Мирфак** Мирфак *(Персей йолдызлыгында* α *йолдызы).*

**Мицар** Мицар *(Җидегәннең* ζ *йолдызы).*

**Млечный путь** Киек Каз юлы *(күк йөзен икегә бүлеп үткән аксыл юл; күп санлы үтә ерак йолдызлардан һәм томанлыклардан тора; безнең Галактиканың спираль канатларыннан гыйбарәт. Урта Азия халыклары аны Саман, ягъни Салам юлы дип атый).*

**Море Влажности** Дымлы диңгез *(Айда);* **к. моря лунные.**

**Море Волн** Дулкыннар диңгезе *(Айда);* **к. моря лунные.**

**Море Восточное** Көнчыгыш диңгезе *(Айда);* **к. моря лунные.**

**Море Дождей** Янгырлар диңгезе *(Айда);* **к. моря лунные.**

**Море Краевое** Кырый диңгез *(Айда);* **к. моря лунные.**

**Море Кризисов (Опасностей)** Кризислар диңгезе, Хәвефле диңгез *(Айда);* **к. моря лунные.**

**Море Мечты** Хыял диңгезе *(Айда);* **к. моря лунные.**

**Море Мирное** Тыныч диңгез *(Айда);* **к. моря лунные.**

**Море Москвы** Мәскәү диңгезе *(Айда);* **к. моря лунные.**

**Море Новое** Яңа диңгез *(Айда);* **к. моря лунные.**

**Море Облаков** Болытлар диңгезе *(Айда);* **к. моря лунные.**

**Море Паров** Пар диңгезе *(Айда);* **к. моря лунные.**

**Море Пены** Күбек диңгезе *(Айда);* **к. моря лунные.**

**Море Плодородия** Уңыш диңгезе *(Айда);* **к. моря лунные.**

**Море Спокойствия** Тынлык диңгезе *(Айда);* **к. моря лунные.**

**Море Холода** Суык диңгезе *(Айда);* **к. моря лунные.**

**Море Ясности** Аязлык диңгезе *(Айда);* **к. моря лунные.**

**Морозовия** Морозовия *(эре астероид).*

**Моря лунные** Ай диңгезләре *(диңгез исеме белән йөртелсәләр дә, Җирдән караганда көлсыман күләгәле булып күренә торган зур таплар, гадәттә эреле-ваклы кратерлар белән чуарланган ташлы тигезлекләр).*

**Муха** Чебен *(йолдызлык исеме).*

## Н

**Наблюдение планет** планеталарны күзәтү.
**Наводка инструмента** инструментны төбәү.
**Надир** надир *(күк сферасында горизонттан түбән урнашкан һәм зениткa капма-каршы нокта).*
**Наклонение орбиты** орбитаның авышлыгы *(планета орбитасы белән эклиптика яссылыгы арасындагы почмак).*
**Население второго типа („старое“)** „карт“ йолдызлар *(безнең Галактика үзәгендәге, гомерләре ягыннан карт булган кызыл гигантлар һәм кыска периодлы цефеидлар).*
**Население первого типа („молодое“)** „яшь“ йолдызлар *(безнең Галактиканың гадәттә кырыена урнашкан, гомерләре ягыннан яшьрәк булган ультрагигант һәм классик цефеидлар).*
**Насос** Насос *(йолдызлык исеме).*
**Нат** Нат *(Үгезбозау йолдызлыгында β йолдызы).*
**Наугольник** Почмаклык *(йолдызлык исеме).*
**Начало года** ел башы.
**Начальный круг склонения** башлангыч авышу түгәрәге.
**Начальный период обращения спутника** ясалма иярченнең башлангыч әйләнү периоды *(ясалма иярченнең орбитага чыгарган вакыттагы периоды).*
**Небесная механика** күк механикасы *(астрономиянең бөтендөнья тартылу көчләрен исәпкә алып, күк җисемнәренең хәрәкәтен тикшерә торган бүлеге).*
**Небесная сфера** күк сферасы *(яктырткычларның торышлары проекцияләнгән, уртасында Җир шары булган сфера).*
**Небесное тело** күк җисеме.
**Небесное тело исскуственное** ясалма күк җисеме.
**Небесный купол (небо)** күк гөмбәзе, күк *(күк сферасының горизонттан югары өлеше).*
**Небесный свод (небосвод)** күк гөмбәзе; **к. небесный купол.**
**Невесомость** авырлык югалу (халәте) *(гравитация кыры механик системага тәэсир иткәндә система кисәкчекләренең яки бөтен системаның таяныч мәйданына басым ясамавы).*
**Невосходящие светила** калыкмый торган йолдызлар (яктырткычлар) *(урынның географик киңлегенә бәйле рәвештә, ул урында горизонт өстендә күренми торган йолдызлар).*
**Неделя** атна.
**Незаходящие светила** батмый торган йолдызлар (яктырткычлар) *(урынның географик киңлегенә бәйле рәвештә, горизонт астына күмелми торган йолдызлар, мәсәлән, Җидегәннәр).*
**Нептун** Нептун *(Кояштан уртача 4496 миллион километр ераклыкта әйләнеп йөри торган, сигезенче урындагы планета; Юпитер төркеменә карый, ике иярчене бар).*
**Нереида** Нереида *(Нептун планетасының иярчене).*
**Нестор** Нестор *(эре астероид).*
**Нивелирование** нивелирлау *(нивелир ярдәмендә Җир өсте нокталарының биеклеге арасындагы аерманы табу).*
**Нижнее соединение** түбәнге кушылыш; **к. соединение планет с Солнцем.**



**„Новоземелие“** „яңа Җир“ *(Айдан караганда Җир планетасының фазасы).*
**Новолуние** яңа Ай *(Айның яңа туар алдыннан булган фазасы).*
**Нониус** нониус *(лимб түгәрәге бүлемнәренең өлешләрен санау өчен махсус җайланма, верньер);* **к. лимб.**
**Ночь** төн *(дәвамлылыгы географик киңлеккә һәм ел вакытларына карап үзгәрә торган, Кояш батканнан алып Кояш чыкканга кадәр булган вакыт аралыгы).*
**Нутация** нутация *(көн-төн тигезлеге нокталарының һәм дөнья полюсларының периодик рәвештә тирбәнеп торуы; төп тирбәнешнең периоды 18 ел 8 айга тигез).*

## О

**Оберон** Оберон *(Уран планетасының иярчене).*
**Облака Магеллановы** Магеллан болытлары *(безнең Галактикадан 150 000 яктылык елы кадәр ераклыктагы ике иярчен галактика; күкнең көньяк ярымшарында күренәләр).*
**Область околополярная** полюс тирәсе, поляр өлкә *(күк сферасының полюсы тирәсендәге өлкә).*
**Облет Луны** Айны әйләнеп очу, әйләнеп үтү.
**Обозначения звезд** йолдызларның тамгаланышы.
**Обращающий слой** әйләндерүче катлау *(Кояш атмосферасының спектр сызыкларын кирегә әйләндерә торган катлавы).*
**Обращение** әйләнү, әйләнеш; әйләнеп йөрү.
**Обсерватория** обсерватория *(астрономик күзәтүләр башкарыла торган гыйльми үзәк).*
**Объектив** объектив *(телескопларның күк җисемнәренә каратылган башындагы линза яки линзалар системасы; рефлекторлы телескопта — параболик көзге).*
**Объектив ахроматический** ахроматик объектив *(төс аберрациясеннән азат булган югары сыйфатлы объектив).*
**Овен** Овен, Кучкар *(зодиакаль йолдызлык исеме, гарәпчәсе Хәмәл).*
**Ограниченная задача трех тел** өч җисем турында чикләнгән мәсьәлә *(күк механикасында ике җисем һәм алар белән чагыштыргысыз кимрәк массалы өченче җисемнең хәрәкәтен тикшерү очрагы).*
**Озеро Смерти** Әҗәл күле *(Айда).*
**Озеро Сновидений** Төшләр күле *(Айда).*
**Океан Бурь** Давыллар океаны *(Айда).*
**Окно окулярное** окуляр тәрәзәсе *(телескопта окуляр биргән барлык нурлар җыела торган тап).*
**Октан** Октан *(йолдызлык исеме).*
**Окуляр** окуляр *(телескопның күз белән карый торган линзасы яки линзалар системасы).*
**Оппозиция планеты** планетаның каршыда торышы, оппозициясе; **к. противостояние.**
**Определение времени** вакыт(ны) билгеләү, үлчәү.
**Оптика** оптика *(1. Физиканың яктылык күренешләрен өйрәнә торган бүлеге; 2. Астрономик инструментлардагы оптик җиһазлар: линзалар, көзгеләр системасы).*

**Оптическая ось трубы** трубаның оптик күчәре *(объективның һәм окулярның оптик үзәкләре аша үтә торган туры).*
**Оптический центр объектива** объективның оптик үзәге *(үзе аша үтүче нурларның юнәлешен үзгәртми торган нокта).*
**Орбита** орбита *(күк җисемнәренең икенче бер җисем тирәли хәрәкәт итү юлы).*
**Орбита гиперболическая** гиперболик орбита *(гипербола буенча хәрәкәт итү траекториясе).*
**Орбита круговая** түгәрәк орбита *(әйләнә буенча хәрәкәт итү траекториясе).*
**Орбита параболическая** параболик орбита *(парабола буенча хәрәкәт итү траекториясе).*
**Орбита полярная** поляр орбита *(ясалма иярченнәрнең Җир полюслары өстеннән уза торган орбитасы).*
**Орбита селеноцентрическая** селеноцентрик орбита *(ясалма күк җисеменең Ай тирәсендә әйләнү орбитасы).*
**Орбита эллиптическая** эллиптик орбита *(эллипс буенча хәрәкәт итү траекториясе).*
**Орбитальная астрономическая обсерватория** орбиталь астрономик обсерватория *(ясалма иярчендә урнаштырылган астрономик станция).*
**Орбитальная научная станция** орбиталь фәнни станция *(Җир, Ай һәм башка планеталар тирәсендә әйләнүче станция).*
**Орел** Каракош *(йолдызлык исеме).*
**Орион** Көянтә, Орион *(йолдызлык исеме).*
**Ориониды** орионидлар *(метеор агышы; октябрьның икенче яртысында күзәтелә, радианты Орион йолдызлыгында урнашкан).*
**Ортодромия** ортодромия *(сферада, мәсәлән Җир өслегендә, ике ноктаны тоташтыручы иң кыска сызык, юл).*
**Осень** осень *(астрономиядә төньяк ярымшарда Кояшның экватордан көньякка авыша башлаган көненнән — 22 нче сентябрьдән алып, Кояшның кышкы торгынлык көненә — 22 нче декабрьга кадәр булган вакыт аралыгы — 89,8 тәүлек. Бу — астрономик көз дип атала).*
**Ось вращения Земли** Жирнең әйләнү күчәре *(Җирнең ике полюсы аркылы үткән геометрик туры сызык).*
**Ось Мира** Дөнья күчәре *(күзәтүченең күзе аркылы үтеп, Дөньяның ике полюсын тоташтыручы һәм Җирнең әйләнү күчәренә параллель булган күчәр; күк сферасының күренмә әйләнү күчәре).*
**Ось полярная (часовая)** поляр күчәр (сәгатьләр күчәре) *(экваториаль телескопның Дөнья полюсына юнәлгән күчәре).*
**Ось склонений** авышулар күчәре *(инструментның авышу почмакларын үзгәртергә мөмкинлек бирә торган күчәр).*
**Отлив** су чигенеше; су кимү, су кайту *(Ай һәм Кояшның тарту көчләре тәэсирендә океан һәм ачык диңгез суларының күтәрелеп 6 сәгать чамасы вакыт үткәч яңадан кимүе).*
**Ошибка вероятная** ихтимал ялгыш *(уртача ялгышны 0,6745 кә тапкырлап табылган зурлык).*
**Ошибки индивидуальные** күзәтүче ялгышлары, индивидуаль ялгышлар *(күзәтүдә һәркемнең үзенә генә хас хаталар).*
**Ошибки инструментальные** инструмент ялгышлары *(һәр инструментның үзенә генә хас хаталар).*
**Ошибки систематические** системалы ялгышлар *(билгеле бер кагыйдәгә буйсына торган хаталар; кагыйдәсен белгәндә, аларның тәэсиреннән котылып була).*



**Ошибки случайные** очраклы ялгышлар *(алдан күреп булмый торган хаталар; аларның нәтиҗәгә тәэсирен беркадәр киметү өчен, күп санлы материалны тикшерергә, гомумиләштерергә туры килә).*
**Ошибки средние** уртача ялгышлар *(аерым күзәтүләрнең чын ялгышларын күзәтүләр саныннан алынган квадрат тамыр зурлыгына бүлеп табыла).*

## П

**Павлин** Тавис *(йолдызлык исеме).*
**Падающие звезды** атылган йолдызлар; **к. звездный дождь.**
**Паллада** Паллада *(эре астероид).*
**Параболическая скорость** параболик тизлек *(күк җисеменең парабола буенча хәрәкәт итү тизлеге; Җирдән җибәрелгән ракеталар өчен — икенче космик тизлек).*
**Параллакс** параллакс *(күзәтүче базисы очларыннан караганда әйбернең күчену почмагы).*
**Параллакс годичный** еллык параллакс *(яктырткычтан караганда күзәтү юнәлешенә перпендикуляр булган Җир орбитасы радиусының күренү почмагы).*
**Параллакс горизонтальный** горизонталь параллакс *(яктырткычтан караганда күзәтү юнәлешенә перпендикуляр булган Җир радиусының күренү почмагы).*
**Параллакс нитей** җепләр параллаксы *(астрономик трубада).*
**Параллакс Солнца (средний экваториальный горизонтальный параллакс Солнца)** Кояш параллаксы *(Җир уртача ераклыкта торганда Кояш үзәгеннән күзәтүчегә Җир радиусы күренә торган почмак).*
**Параллакс суточный** тәүлеклек параллакс *(түбәсе яктырткыч үзәгендә булып, яклары Җирнең үзәгенә һәм Җир өстендәге күзәтүчегә юнәлгән почмак).*
**Параллаксы тригонометрические** тригонометрик параллакслар *(почмакларны турыдан-туры үлчәп табылган параллакслар).*
**Параллаксы звезд спектральные** йолдызларның спектраль параллакслары *(спектрны күзәтү юлы белән табылган параллакслар).*
**Параллактическая (экваториальная) установка** параллактик (экваториаль) җайланма, инструмент *(бер күчәре дөнья полюсына юнәлтеп куелган телескоп; экваториал).*
**Параллактический треугольник** параллактик өчпочмак *(күк яктырткычы һәм күзәтү базисы төзегән өчпочмак).*
**Параллактическое смещение** параллактик тайпылыш *(күзәтүченең урын алмаштыруы аркасында әйбернең бер читкә тайпылгандай булып күренүе).*
**Параллель** параллель *(экватор яссылыгына параллель яссылыкның Җир шары өслеге белән кисешү сызыгы. Бер параллельдә яткан географик урыннарның киңлеге бердәй була).*
**Параметры орбиты** орбита параметрлары *(күк җисемнәренең икенче бер күк җисеме тирәсендә әйләнгәндәге орбиталарының геометрик элементлары).*

**Парсек (параллакс-секунда)** парсек *(астрономиядә озынлык берәмлеге; Җир орбитасының зур ярымкүчәре 1″ булып күренә торган ара.* 1 парсек = 3,26 *яктылык елы* = $30{,}8 \cdot 10^{12}$ *километр).*

**Паруса** Җилкәннәр *(йолдызлык исеме).*

**Пассажный инструмент** пассаж инструменты *(горизонталь күчәре гадәттә көнчыгыш-көнбатыш юнәлешендә урнаштырылган һәм оптик күчәре меридиан яссылыгында әйләнә ала торган астрономик труба).*

**Патрокл** Патрокл *(астероид).*

**Патруль метеорный** метеор(лар) патруле *(метеорларны күзәтү хезмәте, посты).*

**Пегас** Пегас, Тулпар *(йолдызлык исеме).*

**Пепельный свет Луны** Айның көлсу яктылыгы (көлсыман төсе) *(Ай яңа туган вакытта аның караңгы булып күренергә тиешле урыннарында, Җирнең Кояш нурларын Айга кайтаруы сәбәпле, анда күренә торган көлсу төс).*

**Первая четверть Луны** Айның беренче чиреге.

**Перегрузка** авырлык арту *(механик системага гравитация кыры тәэсир иткәндә, шулай ук тизләнешле хәрәкәт иткәндә система кисәкчекләренең бер-берсенә яки таяныч мәйданына басым көченең артуы).*

**Передача точного времени** төгәл вакыт хәбәр итү *(дөрес вакыт сигналларын радио аркылы халыкка җиткерү).*

**Периастр** периастр *(иярчен йолдыз орбитасының төп йолдызга иң якын ноктасы).*

**Перигалактион** перигалактион *(йолдызларның галактика үзәге тирәли әйләнешләрендә үзәккә иң якын ара).*

**Перигей** перигей *(Җир иярченнәре орбиталарының Җиргә иң якын булган ноктасы).*

**Перигелий** перигелий *(Кояш тирәсендә әйләнеп йөрүче планета һәм башка иярчен орбиталарының Кояшка иң якын булган ноктасы).*

**Период звездный планеты** планетаның йолдызча периоды *(планеталарның Кояш тирәсендә йолдызларга карата бер тулы әйләнеш ясавы өчен киткән вакыт).*

**Период планеты синодический** планетаның синодик периоды *(планеталарның бер-бер артлы килгән бертөрле ике конфигурациясе арасында үткән вакыт).*

**Периодические переменные звезды** периодик үзгәрешле йолдызлар.

**Периселений** периселений *(Ай тирәсендә әйләнүче ясалма күк җисеме орбитасында Айга иң якын булган нокта).*

**Перицентр** перицентр *(иярчен орбитасының төп күк җисеменә иң якын булган ноктасы; перигей, перигелий, һ. б.).*

**Персей** Персей *(йолдызлык исеме).*

**Персеиды** персеидлар *(метеор агышы; июль — август айларында күзәтелә, радианты Персей йолдызлыгында).*

**Петлеобразное движение к. движение планет петлеобразное.**

**Печь** Мич *(йолдызлык исеме).*

**Планетарий** планетарий (1. *Планеталарның бер-берсенә карата торышларын, аларның хәрәкәтен һәм күк йөзен күрсәтә торган аппарат — механик планетарий;* 2. *Планетарий аппараты ярдәмендә демонстрацияләр ясап, астрономиядән лекцияләр укыла торган белем бирү учреждениесе).*

**Планеты** планеталар *(Кояш тирәсендә әйләнә торган шарсыман күк җисемнәре: Меркурий, Венера, Җир, Марс, Юпитер, Сатурн, Уран, Нептун һәм Плутон).*

**Планеты верхние к. верхние планеты.**

**Планеты внешние к. внешние планеты.**

**Планеты внутренние к. внутренние планеты.**

**Планеты-гиганты** гигант планеталар *(Җиргә караганда күләме зуррак булган планеталар: Юпитер, Сатурн, Уран һәм Нептун).*

**Планеты нижние** түбәнге планеталар *(Җир орбитасы эчендәге планеталар: Меркурий һәм Венера).*

**Планеты типа Земли** Җир тибындагы планеталар *(Җирдәй һәм аннан кечкенәрәк булган планеталар: Венера, Марс, Меркурий).*

**Плейона** Плейона *(Үгезбозау йолдызлыгында 28 нче йолдыз).*

**Плеяды** Иләк, Иләк йолдыз *(Галактикага караган һәм Кояш системасыннан 150 парсек ераклыкта Үгезбозау йолдызлыгында күренә торган, 500 чамасы йолдыздан гыйбарәт тупланыш. Болгар илендә бу йолдызлыкны Өлкәр дип йөрткәннәр).*

**Плоскость горизонта** горизонт яссылыгы, офык яссылыгы, *(күк сферасы үзәге аша үтүче һәм асма юнәлешкә перпендикуляр булган яссылык).*

**Плоскость земной орбиты** Җир орбитасы яссылыгы.

**Плоскость небесного экватора** күк экваторы яссылыгы *(күзәтүче күзе аркылы үткән һәм дөнья күчәренә перпендикуляр булган яссылык).*

**Плотность** тыгызлык *(күк җисеме массасының күләменә чагыштырмасы).*

**Плотность средняя** уртача тыгызлык.

**Плутон** Плутон *(Кояштан 5947 миллион километр ераклыкта, 9 нчы урында әйләнеп йөрүче, иярченсез планета).*

**Повторяемость затмений** тотылуларның кабатлануы; **к. Сарос.**

**Поглощение** йотылу.

**Поглощение межзвездное** йолдызара йотылу *(яктылыкның йолдызара тузанда, газда йотылуы).*

**Подвижная карта неба** күкнең күчмә картасы.

**Подсистемы звезд** йолдыз (ларның) ярымсистемалары *(зуррак системага буйсынган тупланышлар).*

**Позиционный угол** позицион почмак *(ике йолдыз аша үткәрелгән зур түгәрәк белән шул йолдызларның берсе аша үткәрелгән авышулар яссылыгы арасындагы почмак).*

**Показатель цвета к. колориндекс.**

**Покрытие звезд** йолдызларның каплануы *(йолдызларның планета артында калуы, тотылуы).*

**Полдень** төш (вакыты) *(Җир өстендәге ноктадан караганда Кояш үзәгенең югары кульминациядә булу моменты).*

**Полдень истинный** чын төш вакыты *(чын Кояшның меридианнан үтү моменты).*

**Полдень средний** уртача төш вакыты *(уртача Кояшның меридианнан үтү моменты).*

**Поле зрения телескопа** телескопның күрү мәйданы *(телескоп белән караганда күренә торган түгәрәк мәйданы).*

**Поле тяготения** гравитация кыры, тартылыш кыры *(бөтендөнья тартылу көче тәэсир иткән кыр).*

**Полет космический** космик очыш; галәмгә очу.

**Поллукс** Поллукс *(Игезәкләр йолдызлыгында сары төстәге β йолдызы).*

**Полоса полного затмения** тулы тотылу зонасы *(Җир өслегендә Кояш яки Айның тулысынча тотылуы күзәтелә торган полоса).*

**„Полноземелие"** „Тулы Җир" *(Айдан караганда Җир дискысының тулысынча яктырып күренә торган фазасы).*

**Полнолуние** тулы Ай *(Айның Кояш яктырткан ягының безгә түгәрәк булып күренгән фазасы).*

**Полночь** төн уртасы *(Җир өслегендәге ноктага карата Кояш үзәгенең түбәнге кульминациядә булу вакыты).*

**Полночь истинная** чын төн уртасы *(чын Кояшның түбәнге кульминациядә меридианнан үтү моменты).*

**Полночь средняя** уртача төн уртасы *(уртача Кояшның түбәнге кульминациядә меридианнан үтү моменты).*

**Полуденная линия** төшлек сызыгы *(төш вакытында гномоннан, ягъни вертикаль таяктан горизонталь өслеккә төшкән күләгә юнәлеше; меридиан яссылыгының горизонталь яссылык белән кисешү сызыгы).*

**Полуось** ярымкүчәр *(астрономиядә эллиптик орбита күчәренең яртысы).*

**Полуось большая** зур ярымкүчәр *(күк җисеме хәрәкәт итә торган эллиптик орбитаның зур ярымкүчәре озынлыгы).*

**Полуось малая** кече ярымкүчәр *(күк җисеме әйләнеп йөри торган эллиптик орбитаның кечкенә ярымкүчәре озынлыгы).*

**Полутень** ярымкүләгә *(планеталарның Кояшка каршы ягында Кояшның бер өлешеннән генә якты төшкән урын; мәсәлән, Кояш өлешчә тотылганда Җир Ай артындагы ярымкүләгә конусына керә).*

**Полушария** ярымшарлар *(1. Күк сферасы экваторыннан төньякта яки көньякта булган өлешләр; 2. Җир шарының географик экватордан көньякта һәм төньякта булган өлешләре).*

**Полюс Земли** Җир(нең) полюсы *(Җир әйләнү күчәренең Җир өслеге белән кисешү нокталары).*

**Полюс Земли северный** Җирнең төньяк полюсы.

**Полюс Земли южный** Җирнең көньяк полюсы.

**Полюс истинный** чын полюс *(нутация һәм прецессия аркасында полюс хәрәкәт итә торган эллипстагы нокта; анда теге яки бу моментта полюс урнашкан була).*

**Полюс Мира (полюс небесный)** Дөнья полюсы (күк полюсы) *(Дөнья күчәре күк сферасын кисеп үтә торган нокталар).*

**Полюс средний** уртача полюс *(нутация аркасында полюс хәрәкәт итә торган эллипсның үзәге).*

**Полярископ** полярископ *(яктылыкның өлешчә полярлашуын тикшерә торган прибор).*

**Поляризация межзвездная** яктылыкның йолдызара тирәлектә полярлашуы.

**Полярные сияния** котып балкышы, поляр балкыш; төньяк балкышы *(безнең ярымшарда күкнең төньяк өлешендә, Җир өслегеннән 1000 километр биеклектә сирәк һавада була торган яктыру күренеше; башкортларда аҗагай дип тә йөртелә).*



**Полярные шапки** поляр бүрекләр, котып бүрекләре; **к. шапки планет.**

**Полярный круг северный** төньяк поляр түгәрәк *(Кояш елына бер генә мәртәбә — 22 нче июньдә баемый торган һәм елына бер генә мәртәбә — 22 нче декабрьда чыкмый торган 66° 33' лы географик параллель).*

**Полярный круг южный** көньяк поляр түгәрәк *(Кояшның елына бер генә мәртәбә — 22 нче декабрьда баемый һәм елына бер генә мәртәбә — 22 нче июньдә чыкмый торган 66° 33′ лы көньяк географик параллель).*

**Полярный радиус Земли** Җирнең поляр радиусы *(Җир шарының үзәген географик полюс белән тоташтыручы туры сызыкның озынлыгы; ул экваториаль радиустан кимрәк).*

**Понижение горизонта** горизонтның түбәнәюе *(диңгез өсте тигезлегеннән билгеле бер биеклектә торып караганда горизонталь яссылык белән диңгез кырыена юнәлгән күзәтү нуры арасындагы почмак; атмосферада рефракция күренеше булу аркасында ул горизонталь сызык белән орынма сызык арасындагы почмакка тигез булмый).*

**Поправка болометрическая** болометрик төзәтмә *(астрономиядә йолдызча зурлыкка болометр белән табылган төзәтмә кертү).*

**Поправка часов** сәгатьне дөресләү *(төгәл вакытны табу өчен сәгать күрсәткәнгә өстәргә кирәк булган уңай яки тискәре вакыт зурлыгы).*

**Посадка мягкая (плавная)** салмак төшү *(космик корабльләрнең һәм ракеталарның планеталарга әкренлек белән төшеп утыруы).*

**Последняя четверть** соңгы чирек *(Айның һәм, гомумән, планеталарның фазасы).*

**Последовательность главная** төп эзлеклелек *(йолдызларны яктырышы, температурасы һәм төсе ягыннан бер тәртипкә салып күрсәтә торган диаграммада төп тармак).*

**Постоянная аберрации** аберрация константасы *(аберрация эллипсының зур ярымкүчәре, почмакча зурлыгы 20″, 47).*

**Постоянная нутации** нутация константасы *(нутация эллипсының зур ярымкүчәре, почмакча зурлыгы 9″, 21)*

**Постоянная рефракции** рефракция константасы *(рефракция зурлыгын табу өчен күренмә зенит ераклыгы тапкырлана торган даими зурлык).*

**Постоянная тяготения (гравитации)** гравитация константасы *(массалары 1 әр грамм булган ике җисемнең 1 сантиметр ераклыктан торып бер-берсенә тартылу көче).*

**Потоки метеоров (метеорные)** метеор (лар) агышы *(күктә бер ноктадан — радианттан чыккан кебек күренә торган метеорлар өере).*

**Пояс астероидов** астероидлар поясы, астероидлар зонасы *(Марс белән Юпитер орбиталары арасында).*

**Пояс Зодиака** Зодиак поясы, Зодиак кыршавы *(зодиакаль йолдызлыклардан торган түгәрәк).*

**Пояс радиационный Земли** Җирнең радиация поясы *(Җир-*

*дән аның биш диаметры кадәр ераклыкка сузылган һәм электр корылмалы кисәкчәләрдән — электроннар белән протоннардан гыйбарәт эчке һәм тышкы пояслар).*

**Пояс частиц высоких энергий к. пояс радиационный.**

**Поясное время к. время поясное.**

**Предварение равноденствий** көн-төн тигезлегенең иртәләве *(прецессия хәрәкәте аркасында көн-төн тигезлегенең иртәрәк килүе);* **к. прецессия.**

**Предел зрения** күрә алу чиге; күз үткерлеге чиге *(күз күрә ала торган иң тоныҡ йолдыз).*

**Преломление света** яктылык (ның) сыну (ы).

**Прецессия** прецессия *(Җир экваторы һәм эклиптика яссылыкларының йолдызларга карата хәрәкәт итүе сәбәпле язгы көн-төн тигезлеге нокталарының акрынлык белән күчүе; Дөнья күчәренең йолдызларга карата юнәлешен үзгәртә торган бу күчешнең периоды* 26 000 *елга тигез).*

**Прецессия годовая** еллык прецессия.

**Прецессия лунно-солнечная** Ай-Кояш прецессиясе.

**Приам** Приам *(астероид).*

**Приемник радиоизлучения** радионурланыш алгычы *(космик радионурланышны кабул итә торган прибор).*

**Приземление** Җиргә төшү *(космик корабльнең Җиргә килеп утыруы).*

**Призма объективная** объектив призмасы *(йолдыз спектрларын фотога төшергәндә телескоп объективы каршына куела торган зур призма).*

**Призма окулярная** окуляр призмасы.

**Прикладной час** соңару вакыты *(Айның кульминациясеннән соң диңгез суы иң биек күтәрелгән моментка кадәр үткән вакыт).*

**Прилив** диңгез суы күтәрелеше; күтәрелеш *(Ай һәм Кояшның тарту көче тәэсирендә диңгез-океан суларының күтәрелүе).*

**Прилив квадратурный** квадратура (су) күтәрелеше *(Ай квадратураларыннан соң* 1—2 *көн үткәч, диңгез суына Ай һәм Кояш тәэсирләре капма-каршы булган вакытлардагы су күтәрелеше).*

**Прилив сизигийный** сизигий (су) күтәрелеше *(яңа Ай туып яки Ай тулып, сизигийдан соң* 1—2 *көн үткәч булган аеруча көчле су күтәрелеше).*

**Приливообразующая сила** су күтәрелеше хасил итүче көч; күтәрелеш хасил итүче көч.

**Продолжительность времен года** ел вакытлары озынлыгы.

**Прилунение** Айга төшү *(космик корабльләрнең һәм автомат станцияләрнең Айга барып утыруы).*

**Принцип Доплера** Доплер принцибы *(яктылык чыганагы белән күзәтүченең ара ераклыгы үзгәргән вакытта спектрдагы сызыкларның күчүе турындагы кагыйдә. Бу принцип астрономик объектларның күпме тизлек белән якынаю яки ерагаюын белергә мөмкинлек бирә).*

**Проксима** Проксима **к. Ближайшая Центавра.**

**Проницающая сила телескопа** телескопның үткерлеге.

**Пространство мировое** галәм (киңлеге), галәм бушлыгы, галәм пространствосы.

**Противосияние** каршы *балкыш (Кояшка капма-каршы яктагы аксыл яктырыш; Җир шарының газ койрыгы Кояш яктысын чәчүдән килә).*



**Противостояние** каршыда торыш, кара-каршы торыш *(планеталарның Кояш — Җир туры сызыгында Кояшка капма-каршы якта торуы; бу вакытта алар Җиргә аеруча якын киләләр);* **к. оппозиция.**

**Протогалактика** протогалактика, галактика яралгысы.

**Протозвезды** протойолдызлар, йолдыз яралгылары *(шундый ук массалы йолдызларга караганда салкынрак, ләкин вакыт үтү белән эчендәге температуралары берничә миллион градуска җитә торган тотрыксыз хәлдәге күк җисемнәре; йолдыз ясалуның икенче баскычы).*

**Протуберанцы** протуберанецлар (*Кояш хромосферасы катлавыннан ара-тирә атылып чыга торган кызган газ ялкыннары).*

**Протуберанцы древовидные** ябалдашлы протуберанецлар, агачсыман протуберанецлар.

**Протуберанцы изверженные** атылган протуберанецлар.

**Протуберанцы облакообразные** болытсыман протуберанецлар.

**Протуберанцы спокойные** тыныч протуберанецлар.

**Процион** Процион (*Кечкенә Эт йолдызлыгындагы сары төстәге* $\alpha$ *йолдызы).*

**Прохождение Венеры** Венераның узуы *(Венера планетасының караңгы дискы Кояш дискысыннан үтү).*

**„Прямая стена“** „Туры стена“ (*Айда текә озын тау*).

**Прямое восхождение** туры күтәрелү (*Дөнья полюсыннан яктырткыч аша үткәрелгән ярымтүгәрәк яссылыгы белән Дөнья полюсыннан экватордагы көн-төн тигезлеге ноктасы аша үткәрелгән ярымтүгәрәк яссылыгы арасындагы почмак; экваториаль координаталар системасында яктырткычның бер координатасы булып хезмәт итә).*

**Прямое движение планет к. движение планет прямое.**

**Пыль межзвездная** йолдызара тузан, космик тузан; **к. космическая пыль.**

**Пульсары** пульсарлар *(пульсацияле космик радионурланыш чыганаклары; аларны атом төше тыгызлыгындагы һәм Җирдән дә кечкенәрәк йолдызлар дип уйлыйлар).*

**Путешествие межпланетное** планетаара сәяхәт.

**Пятна солнечные** Кояш таплары (*Кояш фотосферасында* 11 *еллык период белән барлыкка килеп һәм югалып тора торган караңгырак урыннар).*

# Р

**Равновесие лучевое к. лучевое равновесие.**

**Равноденствие** көн-төн тигезлеге *(елга ике мәртәбә —* 21 *нче мартта һәм* 23 *нче сентябрьдә көн озынлыгы белән төн озынлыгының тигезләшүе).*

**Радиант** радиант (*„йолдыз яңгыры“ вакытында күк йөзендә метеор эзләре „кисешкән“ нокта*).

**Радиационные пояса к. пояс радиационный Земли.**

**Радиоастрономия** радиоастрономия *(астрономиянең космостан килә торган радионурланышларны, һәм Җирдән җибәрелеп күк җисеменнән кире кайтарылган сигналларны өйрәнеп, күк җисемнәрен тикшерә торган бүлеге).*

**Радиогалактика** радиогалактика *(интенсив рәвештә синхрон радиодулкыннар таратучы галактикалар).*

**Радиозвезды** радиойолдызлар *(радиодулкыннар тарата торган йолдызлар; аларның күбесе оптик телескоптан күренми).*

**Радиоизлучение внегалактическое** (галактикадан тыш радионурланыш.

**Радиоизлучение тепловое** термик радионурланыш *(күк җисемнәренең, температура күтәрелү нәтиҗәсендә, радиодулкыннар чыгаруы).*

**Радиоинтерферометр** радиоинтерферометр *(радиодулкыннар интерференциясе методы белән төрле нурланыш чыганакларының почмакча зурлыкларын үлчәү һ. б. өчен хезмәт итә торган интерферометр).*

**Радиолокация Венеры** Венераны радиолокацияләү *(тар бәйләм рәвешендә радиодулкыннар җибәреп, кайтарылган сигналлар нигезендә Венера өслеген өйрәнү).*

**Радиоокно** радиотәрәзә *(атмосфера аша үтә торган ультракыска дулкыннар диапазоны).*

**Радиотелескоп** радиотелескоп *(күк җисемнәре чыгарган яки алардан кайтарылган радиодулкыннарны кабул итүче җайланма).*

**Радиус-вектор** радиус-вектор *(астрономиядә бу термин планета белән Кояш үзәкләрен тоташтырган турысызыклы кисемтә озынлыгы мәгънәсенә туры килә).*

**Разрешающая сила телескопа** (телескопның аеру сәләте, телескопның үткерлеге; **к. проникающая сила телескопа.**

**Рак** Кысла *(йолдызлык исеме; гарәпчәсе Сәратан).*

**Ракета межпланетная** планетаара ракета.

**Ракета метеорологическая** метеорологик ракета, метеорология ракетасы *(һава хәлен күзәтү һәм өйрәнү өчен хезмәт итә торган ракета).*

**Ракета-носитель** йөртүче ракета *(ракетаның төп өлешен — приборлар бүлеген яки космик корабльне орбитага чыгару өчен хезмәт итә торган буыннары).*

**Ракета многоступенчатая** күп буынлы ракета *(бер-бер артлы тоташтырылган берничә өлештән торган ракета. Ракета беренче буындагы ягулык яну исәбенә күтәрелә һәм ул буынны аерып калдыра, шуннан соң икенче буын эшли башлый һ. б. Нәтиҗәдә ракетаның тизлеге арткannан-арта бара).*

**Рас Альгети** Рас Альгети *(Геркулес йолдызлыгының α йолдызы).*

**Рас Альхаге** Рас Альхаге *(Еланлы йолдызлыгының α йолдызы).*

**Рассеянные (диффузные) скопления** таркау (диффуз) тупланышлар.

**Расстояние афелия** афелий ераклыгы *(иярчен җисемнең орбитада Кояштан иң ерак арасы).*

**Расстояние зенитное к. зенитное расстояние.**

**Расстояние перигелия** перигелий ераклыгы *(иярчен җисемнең орбитада Кояшка иң якын арасы).*

**Расстояние полярное** поляр ераклык *(йолдызның дөнья полюсыннан почмакча ераклыгы).*

**Расстояние стандартное** стандарт ераклык *(йолдызларның ераклыгын һәм аларның башка характеристикаларын чагыштыру өчен кабул ителгән шартлы ераклык берәмлеге—*10 *парсек).*



**Расстояние угловое** почмакча ераклык *(күк сферасында яктырткычның билгеле бер ноктадан почмакча ераклыгы).*

**Расстыкование (расстыковка) кораблей** корабльләрне аеру *(бергә тоташып очкан космик корабльләрне бер-берсеннән ычкындыру).*

**Регистрирующий (безличный) микрометр** регистрацияләүче микрометр *(йолдызларны күзәткәндә шәхси хаталардан котылырга мөмкинлек бирә торган микрометр).*

**Регул** Регул *(Арслан йолдызлыгында ак төстәге α йолдызы).*

**Резец** Кискеч *(йолдызлык исеме).*

**Рефлектор** рефлектор *(объективы параболик батынкы көзгедән торган телескоп; көзгеле телескоп);* **к. зеркальный телескоп.**

**Рефрактор** рефрактор *(объективы линзалар системасыннан торган телескоп).*

**Рефрактор-астрограф** рефрактор-астрограф *(күк җисемнәрен күзәтү һәм фотога төшерү өчен билгеләнгән телескоп).*

**Рефракция света в атмосфере** яктылыкның атмосферадагы рефракциясе *(атмосфера аша үткәндә күк яктырткычларының башка ноктада күренүе. Мәсәлән, Ай белән Кояш, үзләре горизонт астында булсалар да, горизонттан югары күренәләр; шуның нәтиҗәсендә Казанда көн-төн тигезлеге вакытында көн озынлыгы* 12 *сәгать урынына* 12 *сәгать* 7 *минут чамасы була).*

**Рея** Рея *(Сатурн планетасының иярчене).*

**Ригель** Ригель *(Орион йолдызлыгында ак төстәге β йолдызы).*

**Рога** мөгезләр *(планета яки аларның иярченнәренең беренче һәм соңгы чирекләрендә күренгән очлары).*

**Рыбы** Балыклар *(зодиакаль йолдызлык исеме, гарәпчәсе Хут).*

**Рысь** Селәүсен *(йолдызлык исеме).*

## С

**Садальмелик** Садальмелик *(Сукояр йолдызлыгында α йолдызы).*

**Самоизлучение** үзнурланыш.

**Самосветящиеся тела** үзләре яктырта торган жисемнәр *(мәсәлән, йолдызлар).*

**Сарос** сарос *(Кояш һәм Ай тотылуларның кабатлану периоды: 18 ел 11 көн).*

**Сатурн** Сатурн *(Кояштан 1 427 миллион километр ераклыкта, 6 нчы урында әйләнеп йөри торган гигант планета; яссы боҗрасы һәм 10 иярчене бар);*

**Сверхгалактика** супергалактика, үтә зур галактика.

**Сверхгигант** супергигант *(яктылык егәрлеге үтә зур булган йолдыз).*

**Сверхновая (звезда) к. звезды сверхновые.**

**Светила восходящие** калка торган яктырткычлар *(теге яки бу географик киңлектә горизонт өстендә дә күренә торган күк яктырткычлары).*

**Светила заходящие** бата торган яктырткычлар.

**Светила незаходящие** батмый торган яктырткычлар.

**Светило** яктырткыч, күк яктырткычы.

**Светило небесное** күк яктырткычы *(йолдызлар, планеталар. Кояш, Ай һ. б.)*

**Светило центральное** үзәк яктырткыч (*мәсәлән, планеталар өчен Кояш*).

**Светимость звезды** йолдызның яктыртучанлыгы, җетелеге (*йолдыз чыгарган яктылык егәрлегенең Кояш яктылыгына караганда ничә мәртәбә зур икәнен күрсәткән сан*).

**Светлота** аклык.

**Световой год к. год световой.**

**Светосила объектива** объективның яктырту сәләте (*объектив биргән сурәтнең яктылык дәрәҗәсен объектның яктылыгына чагыштырып табыла; зуррак диаметрлы һәм фокус ераклыгы кыскарак булган объективның яктырту сәләте зуррак*).

**Светочувствительность** яктыга сизгерлек; якты сизүчәнлек.

**Свечение** елкылдау.

**Сгущение** куерма.

**Север** төньяк, географик төньяк (*чын горизонтның күк меридианы белән кисешкән һәм Дөньяның төньяк полюсына якын булган нокта*).

**Северная Корона (Северный Венец)** Төньяк Таж (*йолдызлык исеме*).

**Секстант** Секстант (*йолдызлык исеме*).

**Секстант** секстант (*яктырткычларның горизонттан почмакча ераклыкларын үлчи торган оптик прибор*).

**Секстант космический** космик секстант (*почмак үлчәү эшләрен космик корабль яки скафандр эчендә килеш башкару өчен җайланган секстант*).

**Секунда** секунд (*почмак һәм вакыт үлчәү берәмлеге*).

**Секунда звездная** йолдызча секунд (*йолдыз тәүлегенең 1/86000 өлеше*).

**Секунда солнечная** кояшча секунд (*тропик елның 1900, январь 0, 12 сәгать моменты өчен 1/315 56925, 9747 өлеше*).

**Селенография** селенография (*Ай өслеген өйрәнә торган фән*).

**Селенология** селенология (*планетологиянең бер бүлеге; Айның рельефын, матдә составын һ. б. өйрәнә*).

**Сетка** Челтәр (*йолдызлык исеме*).

**Сетка нитей** җепләр челтәре (*телескопта*).

**Сигналы точного времени** дөрес вакыт сигналлары (*төгәл вакытны халыкка җиткереп тору өчен радио аша бирелә торган шартлы сигналлар*).

**Сидерический период обращения Земли** Җир әйләнешенең сидерик периоды; **к. звездный год.**

**Сизигий** сизигий (*яңа һәм тулы Ай фазалары*).

**Сила возмущающая** (хәрәкәт) үзгәртүче көч, пертурбация көче.

**Сила приливная к. приливообразующая сила.**

**Сила тяжести** авырлык көче.

**Симеиза** Симеиза (*астероид*).

**Синодический период обращения Земли** Җир әйләнешенең синодик периоды.

**Сириус** Сириус (*Зур Эт йолдызлыгында ак төстәге α йолдызы*).

**Сиррах** Сиррах (*Андромеда йолдызлыгында α йолдызы*).

**Система гелиоцентрическая к. гелиоцентрическая теория.**

**Система геоцентрическая к. геоцентрическая теория.**



**Система координат горизонтальная** горизонталь координаталар системасы (*математик горизонтка карата алынган система; бу системада бер координата итеп яктырткычның биеклеге, икенчесе итеп азимут зурлыгы алына*).

**Система координат экваториальная** экваториаль координаталар системасы (*күк экваторы яссылыгына карата алынган координаталар системасы; бу системада бер координата итеп почмакча авышу, икенчесе итеп туры күтәрелеш алына*).

**Система местная** җирле система, локаль система.

**Система Мира** Дөнья системасы.

**Система неподвижная** хәрәкәтсез система; кузгалмас система.

**Система ориентировки** ориентация системасы, бору-юнәлтү системасы (*космонавтикада*).

**Система подвижная** хәрәкәтчел система.

**Система солнечная** Кояш системасы; **к. солнечная система.**

**Системы кратные** кабатлы системалар (*йолдызлар*).

**Склонение** авышу (*яктырткычның күк экваторына кадәр булган почмакча ераклыгы; экваториаль системада бер координата*).

**Склонение восточное** көнчыгышка авышу (*координата*).

**Склонение западное** көнбатышка авышу (*координата*).

**Склонение магнитное** магнит авышуы (*урынның географик һәм магнит меридианнары арасындагы почмак*).

**Скопление звездное** йолдыз (лар) тупланышы (*бер-берсенә якын булып күренә торган һәм бер системага кергән төркем йолдызлар*).

**Скопления рассеянные** таркау йолдыз тупланышлары (*гадәттә төп эзлеклелектәге уннарча, йөзләрчә йолдыздан торган һәм үзәккә таба беркадәр ультрагигантлар булган сирәк тупланышлар*).

**Скопления галактические** галактик тупланышлар, галактика тупланышлары; **к. скопления рассеянные.**

**Скопления шаровые** шарсыман тупланышлар (*йөз меңнәрчә йолдыздан торган умарта күче рәвешендәге йолдыз тупланышлары*).

**Скорость диссипации** диссипация тизлеге (*җисемнең яки молекуланың теге яки бу күк җисеменнән аерылып китүе өчен кирәк булган башлангыч критик тизлек*).

**Скорость космическая вторая (относительно Земли)** икенче космик тизлек (*Җир өслеге тирәсендә хәрәкәт итә башлап, Җир тартуын җиңү өчен җисемгә бирелергә тиешле иң кечкенә тизлек — 11,19 км/сек. Икенче космик тизлек алган җисем Җиргә карата парабола буенча хәрәкәт итә*); **к. параболическая скорость.**

**Скорость космическая первая** беренче космик тизлек (*җисемгә Җирдән аерылып китеп аның иярчененә әйләнүе өчен кирәкле иң кечкенә башлангыч горизонталь тизлек — 7,91 км/сек*).

**Скорость космическая третья** өченче космик тизлек (*Җир өслеге тирәсендә хәрәкәт итә башлап, Җир тартуын, аннары Кояшның тарту көчен җиңеп, Кояш системасын ташлап китә алсын өчен, җисемгә бирелергә тиешле иң кечкенә башлангыч тизлек — 16,7 км/сек*).

**Скорость критическая (убегания)** критик тизлек; **к. скорость диссипации.**

**Скорость лучевая к. лучевая скорость.**
**Скорость начальная** башлангыч тизлек.
**Скорость параболическая к. параболическая скорость.**
**Скорость пространственная** пространстводагы тизлек (*тангенциаль тизлек белән нур буенча тизлекнең результанты*).
**Скорость радиальная** радиаль тизлек (*радиус буенча тизлек компоненты*).
**Скорость света** яктылык тизлеге (*электромагнитик дулкыннарның вакуумда таралу тизлеге — 299 792,5 ± 0,4 км/сек*).
**Скорость секторная** сектор тизлеге (*күк механикасында кулланыла торган бу шартлы зурлык Кеплер законыннан табыла; иярченнең берәр ноктадагы тизлеге белән шул нокта аша үтүче орынмага әйләнү үзәгеннән төшерелгән перпендикуляр тапкырчыгышының яртысына тигез*).
**Скорость тангенциальная** тангенциаль тизлек (*йолдызның Җиргә карата булган үз хәрәкәтенең тизлеге*).
**Скорпион** Чаян (*Йолдызлык исеме*).
**Скульптор** Скульптор (*Йолдызлык исеме*).
**Следящая система** күзәтү системасы (*ясалма күк җисемнәренең очуын күзәтеп торучы приборлар, постлар системасы*).
**Служба Солнца** Кояшны күзәтү хезмәте, Кояш патруле.
**Служба точного времени** төгәл вакыт Идарәсе (*дөрес вакытны белү, аны үзгәртмичә саклау һәм радио аркылы тапшырып тору эшләрен үти торган бюро*).
**Служба широты** киңлекне күзәтү хезмәте.
**Смещение красное к. красное смешение.**
**Смещение фиолетовое** миләүшә төскә тайпылыш (*Доплер эффекты нәтиҗәсендә килеп чыга торган күренеш; кызылга тайпылышның киресе*); **к. красное смещение** һәм **принцип Доплера.**
**Собирательная способность телескопа** телескопның туплау сәләте (*телескоп объективы мәйданының күзе мәйданына чагыштырмасы*).
**Соединение планеты с Солнцем** планетаның Кояш белән кушылуы (кушылыш) (*планета Кояш дискының алгы яки арткы ягыннан үткәндә Кояш, планета һәм Җирнең бер туры сызыкта булуы*).
**Созвездие** йолдызлык (*күкнең билгеле бер шартлы чик эчендәге мәйданда күренгән, ләкин бер физик системага кермәгән йолдызлар*).
**Созвездия зодиакальные** зодиакаль йолдызлыклар: **к. зодиак.**
**Солнечная активность** Кояш (ның) активлыгы (*Кояшта тапларның, протуберанецларның, бигрәк тә хромосфера кабынышларының гадәттәгегә караганда бик нык артуы*).
**Солнечная корона** Кояш тажы (*Кояш атмосферасының иң югары сирәк катлавы; плазмадан гыйбарәт, кинетик температурасы 10⁶ К. Кояш тотылганда күзәтелә*).
**Солнечная постоянная** Кояш константасы (*Җирнең Кояш нурларына перпендикуляр булган өслегенең һәр квадрат сантиметрына төшә торган Кояш энергиясе ≈ 2 кал/см²·мин*).
**Солнечная система** Кояш системасы (*безнең Галактиканың кырыеннан аның ¹/₃ диаметры кадәр ераклыкта әйләнеп йөрүче, үзәгендә Кояш урнашкан, 9 планетадан, 1700 чамасы астероидтан, йөзләрчә кометадан һәм исәпсез-хисапсыз метеор кисәкчекләрдән торган күк җисемнәре системасы*).



**Солнечное радиоизлучение** Кояш(ның) радионурланышы (*Кояшның активлыгы артканда Җирдә төрле физик күренешләр: магнит давыллары, поляр балкыш һ. б. китереп чыгара торган 1—12 сантиметрлы радиодулкыннар*).
**Солнечные батареи** Кояш батареялары (*космик ракета, автомат станция яки ясалма иярченнәрдә Кояш яктысы энергиясен электр энергиясенә әйләндерә торган фотоэлементлар батареясы*).
**Солнечные пятна к. пятна солнечные.**
**Солнечные часы горизонтальные** горизонталь Кояш сәгате (*циферблаты горизонталь урнашкан, э күләгә бирә торган күрсәткече аңа урынның географик киңлеге кадәр почмак ясап куелган борынгы сәгать*).
**Солнечные часы экваториальные** экваториаль Кояш сәгате (*циферблаты экватор яссылыгына параллель урнашкан Кояш сәгате*).
**Солнечный „ветер“** Кояш „җиле“ (*Кояштан радиаль юнәлештә аерылып китә торган плазма; тизлеге секундка берничә йөз километрга җитә*).
**Солнце** Кояш (*безнең планеталар системасының үзәгендә урнашкан, Җиргә караганда 332 000 тапкыр зуррак массалы сары йолдыз*).
**Солнце спокойное** тыныч Кояш (*Кояшның активлыгы кимегән вакыт*).
**Солнце среднее** уртача Кояш (*эклиптика буенча ел дәвамында тигезсез хәрәкәт итүче чын Кояш урынына кабул ителгән уйланма Кояш; чын Кояшның уртача тизлеге белән хәрәкәт итә дип алына*).
**Солнцестояние зимнее** кышкы Кояш торгынлыгы; **к. день солнцестояния.**
**Солнцестояние летнее** җәйге Кояш торгынлыгы; **к. день солнцестояния**
**Сомнеровы линии** Сомнер сызыклары (*Җир өслегендә күк яктырткычы бер үк биеклектә күренгән нокталарны тоташтыручы сызыкның бер кисемтәсе; ул туры сызык дип кабул ителә*).
**Спектр вспышки** кабыныш спектры (*Кояш хромосферасы астында яткан юка катлауның спектры; ул Кояш тулысынча тотылганда берничә секундка гына күренеп ала*).
**Спектроболометр** спектроболометр (*спектрның төрле өлешләрендә нурлар энергиясен үлчи торган болометр*).
**Спектрогелиограмма** спектрогелиограмма; **к. спектрогелиограф.**
**Спектрогелиограф** спектрогелиограф (*Кояш өслеген тар спектраль интервалларда фотога төшерә, ягъни спектрогелиограмма ала торган спектрографлы телескоп*).
**Спектрограмма** спектрограмма (*яктылык спектрының фоторәсеме*).
**Спектрограф призменный** призмалы спектрограф (*күк яктырткычы спектрын фотога төшерү приборы*).
**Спектроскоп** спектроскоп (*күк яктырткычларының спектрын күзәтү өчен хезмәт итә торган прибор*).
**Спектроскоп дифракционный** дифракцион спектроскоп (*диф-*

*ракцион рәшәткә параметрларына карап,* 1 100 Å *дан бернечә* Å *га кадәр спектр өлкәләрен тикшерү өчен кулланыла торган спектроскоп).*

**Спектроскоп прямого зрения** турыдан-туры күзәтүле спектроскоп.

**Спектрофотометр** спектрофотометр *(яктырткычтан килгән төрле озынлыктагы яктылык дулкыннарының интенсивлыгын үлчи торган фотометр).*

**Спика** Спика *(Кыз йолдызлыгында ак төстәге α йолдызы).*

**Спикулы** спикулалар *(Кояш хромосферасындагы агынтылар).*

**Спутник** иярчен *(планеталар тирәсендә әйләнеп йөрүче күк җисеме яки ясалма аппарат; бу термин хәзер Кояш тирәсендә әйләнүче планеталарга карата да кулланыла).*

**Спутник искусственный** ясалма иярчен, спутник *(Җир, Ай һәм башка планеталар тирәсендә әйләнгәндә фәнни тикшеренү эшләре алып бару өчен хезмәт итә торган станция).*

**Спутник метеорологический** метеорологик иярчен *(атмосфераның төрле катлауларындагы һава хәлен күзәтү һәм ул мәгълүматларны җиргә хәбәр итеп тору өчен җибәрелгән ясалма иярчен).*

**Спутник обратный** кире (хәрәкәтле) иярчен *(планетаның күчәр тирәли әйләнү юнәлешенә каршы хәрәкәт итә торган иярчен).*

**Спутник прямой** туры (хәрәкәтле) иярчен *(планетаның күчәр тирәли әйләнү юнәлеше белән бер якка әйләнә торган иярчен).*

**Спутник связи** элемтә иярчене *(радио, телевидение тапшыруларын ерак араларга җиткезү өчен хезмәт итә торган иярчен).*

**Спутник стационарный** стационар иярчен *(планета тирәсендә почмакча әйләнү тизлеге планетаның, мәсәлән Җирнең, тәүлеклек әйләнешенә туры килгән һәм экватор яссылыгында әйләнә торган ясалма иярчен; ул күк йөзендә билгеле бер урында тора.)*

**Старый стиль** иске стиль; **к. календарь Юлианский.**

**Статистика звездная** йолдызлар статистикасы *(төрле йолдызларны исәпкә алу нигезендә йолдыз системаларының төзелешен өйрәнү).*

**Стереокомпаратор** стереокомпаратор *(күк йөзенең бер үк урыны төшерелгән фоторәсемнәрдәге аерманы табу, шул исәптән андагы кечкенә планеталарны эзләү өчен хезмәт итә торган аппарат).*

**Столовая Гора** Яссы Тау *(йолдызлык исеме).*

**Стороны горизонта** дөнья яклары *(горизонтның төп дүрт ноктасы: төньяк — N, көньяк — S, көнчыгыш — O, көнбатыш — W).*

**Стороны света** дөнья яклары; **к. стороны горизонта.**

**Стояние планеты** планета(ның) торгынлыгы *(планетаның чагыштырма хәрәкәтендә тикторыш моментлары; туры хәрәкәттән чигенүгә күчкәндә һәм, киресенчә, туры хәрәкәткә күчәр алдыннан күзәтелә).*

**Стратосфера** стратосфера *(Җир атмосферасының тропосфера һәм мезосфера катлаулары арасындагы, 40—50 километр биеклектәге катлавы; температурасы — нульдән түбән 40—50° С).*

**Стрела** Ук *(йолдызлык исеме).*

**Стрелец** Укчы *(йолдызлык исеме; гарәпчәсе Кавәс).*



**Стыкование космических кораблей** космик корабльләрне (бер-берсенә) тоташтыру.

**Субгиганты** субгигантлар *(гигант йолдызлардан бераз кечкенәрәк йолдызлар).*

**Субкарлики** субкәрләләр *(төп эзлеклелектәге йолдызлардан тонырак йолдызлар).*

**Сумерки** эңгер-меңгер *(Кояш баеганнан алып шәфәкъ баткачны һәм таң беленә башлаганнан алып Кояш чыкканчы булган вакыт).*

**Сумерки астрономические** астрономик эңгер-меңгер *(Кояш горизонт астына 18° төшкәнгә кадәр сузыла; бу вакытта диңгез суднолары бары кара җирне генә күрә ала).*

**Сумерки гражданские** халыкча эңгер-меңгер *(Кояш баеп горизонт астында 7° төшкәнгә кадәр сузылган вакыт).*

**Сумерки навигационные** навигацион эңгер-меңгер *(Кояшның горизонт астында 7°—12° түбән булган вакыты; бу вакытта диңгез суднолары бер-берсен күрә ала).*

**Сутки звездные** йолдызча тәүлек *(Җир шарының үз күчәрендә йолдызларга карата бер тулы әйләнеп чыгуы өчен киткән вакыт. Ул Кояшча тәүлектән бераз кыскарак булып, Кояшча вакыт белән 23 сәгать 56 минут 4,091 секундка тигез).*

**Сутки солнечные** Кояшча тәүлек *(Җир шарының үз күчәрендә Кояшка карата бер тулы әйләнеш ясавы өчен киткән вакыт).*

**Сутки солнечные истинные** чын Кояшча тәүлек *(Кояш дискы үзәгенең бер-бер артлы ике югары кульминациясе арасын узар өчен киткән вакыт).*

**Сутки средние** уртача Кояшча тәүлек *(чын Кояшча тәүлекләрнең бер ел дәвамындагы уртача кыйммәте).*

**Суточное вращение Земли** Җирнең тәүлеклек әйләнеше *(үз күчәре тирәсендә).*

**Суточный ход часов** сәгатьнең тәүлеклек йөреше *(сәгатьнең бер тәүлек эчендә күпмегә алга китүен яки артка калуын күрсәткән зурлык).*

**Сферический двуугольник** сферик икепочмак(лык).

**Сферический треугольник** сферик өчпочмак.

**Сферический избыток к. избыток сферический.**

# Т

**Тавриды** тавридлар *(метеор агышы; октябрь — ноябрь айларында күзәтелә, радианты Үгезбозау йолдызлыгында урнашкан).*

**Телеметеориты** телеметеоритлар *(телескоп аша гына күренә торган вак метеоритлар).*

**Телеметрия** телеметрия *(космик станцияләрдә һәм корабльләрдә автоматлар ярдәмендә үткәрелгән фәнни үлчәү эшләре турында Җиргә хәбәр итү һәм аппаратларны Җирдән торып идарә итү).*

**Телескоп** Телескоп *(йолдызлык исеме).*

**Телескоп** телескоп *(күк җисемнәрен күзәтү өчен хезмәт итә торган астрономик оптик прибор).*

**Телескоп зеркальный** көзгеле телескоп; рефлектор; **к. рефлектор.**

**Телескоп менисковый** менисклы телескоп *(Максутов телескобы).*

**Телескоп рефлекторный к. рефлектор.**

**Телескоп-рефрактор к. рефрактор.**

**Телескоп школьный** мәктәп телескобы *(мәктәпләрдә астрономик күзәтүләр үткәрү өчен билгеләнгән һәм аз зурайтулы телескоп).*

**Телец** Үгезбозау (йолдызлык исеме; гарәпчәсе Сәвер, төркидә Бугай).

**Теллурий** теллурий *(Җирнең Кояш тирәсендәге еллык һәм үз күчәре тирәсендәге тәүлеклек әйләнешен, шулай ук Ай хәрәкәтен күрсәтә торган уку-өйрәтү әсбабы).*

**Теллурические линии** теллурик сызыклар, Җир сызыклары *(күк җисеме спектрында Җир атмосферасы барлыкка китергән сызыклар).*

**Тело космическое** космик жисем.

**Тело метеорное** метеор жисем.

**Температура кинетическая** кинетик температура *(кисәкчекләр тизлегенең Максвеллча бүленеш параметры).*

**Температура цветовая (спектральная)** спектраль температура *(йолдыз спектрында энергия бүленеше нигезендә хисаплап чыгарылган температура).*

**Температура эффективная** эффектив температура *(йолдызда нурланыш таратучы катлауларның шартлы уртача температурасы).*

**Теодолит** теодолит *(астрономиядә почмакча биеклекне, горизонталь почмакларны һәм башка почмакларны үлчәү приборы).*

**Терминатор** терминатор *(тулы булмаган Ай дискында караңгы һәм якты өлешләрнең чиге).*

**Термическая диссипация атмосферы** атмосфераның термик диссипациясе *(температура югары булу сәбәпле атмосферадагы газ молекулаларының читкә таралып бетүе).*

**Термоядерные реакции** термик-төш реакцияләре *(йолдызлар эчендә бара торган атом әверелеше процесслары; яктылык нурланышын шул реакцияләр тәэмин итә).*

**Тефия** Тефия *(Сатурн планетасының иярчене).*

**Титан** Титан *(Сатурн планетасының иярчене).*

**Титания** Титания *(Уран планетасының иярчене).*

**Точка весеннего равноденствия** язгы көн-төн тигезлеге ноктасы *(эклиптикада язгы көн-төн тигезлеге көнендә Кояшның үзәге булган нокта).*

**Точка весны** яз ноктасы; **к. т. весеннего равноденствия.**

**Точка востока** көнчыгыш ноктасы; **к. стороны света.**

**Точка запада** көнбатыш ноктасы; **к. стороны света.**

**Точка зимнего солнцестояния** кышкы Кояш торгынлыгы ноктасы *(эклиптикада көзге һәм язгы көн-төн тигезлеге нокталары арасының урталыгы).*

**Точка зимы** кыш ноктасы; **к. точка зимнего солнцестояния.**

**Точка лета** җәй ноктасы; **к. точка летнего солнцестояния.**

**Точка летнего солнцестояния** җәйге Кояш торгынлыгы ноктасы *(эклиптикада язгы һәм көзге көн-төн тигезлеге нокталары арасының урталыгы).*



**Точка осени** көз ноктасы; **к. точка осеннего равноденствия.**

**Точка осеннего равноденствия** көзге көн-төн тигезлеге ноктасы *(эклиптикада көзге көн-төн тигезлеге көнендә Кояшның үзәге булган нокта).*

**Точка севера** төньяк ноктасы; **к. стороны света.**

**Точка юга** көньяк ноктасы; **к. стороны света.**

**Точки солнцестояний** Кояш торгынлыгы нокталары; **к. точки зимнего и летнего солнцестояний.**

**Точки равноденствий** көн-төн тигезлеге нокталары; **к. точки летнего и осеннего равноденствий.**

**Треугольник** Өчпочмак *(йолдызлык исеме).*

**Триангуляция** триангуляция *(җир өстендә өчпочмакларны үлчәп, топографик карталар төзү).*

**Тритон** Тритон *(Нептун планетасының иярчене).*

**Тропик Козерога (тропик южный)** Кәҗәмөгез тропигы, Көньяк тропик *(көньяк ярымшарда Кояшның елына бер мәртәбә зенитта була торган —23° 27′ лы географик параллель).*

**Тропик Рака (тропик северный)** Кысла тропигы, Төньяк тропик *(төньяк ярымшарда Кояшның елына бер мәртәбә зенитта була торган —23° 27′ лы географик параллель).*

**Тропический год к. год тропический.**

**Тропосфера** тропосфера *(Җир атмосферасының 8—16 километр калынлыктагы иң аскы катлавы; һава хәле үзгәрешләрен китереп чыгара).*

**Троянская группа малых планет (Троянцы)** кече планеталарның Троя группасы, Троялылар *(Юпитер планетасы тартуы тәэсирендә аның орбитасы буенча диярлек Кояш тирәли әйләнеп йөри торган „юлдашлары“).*

**Труба астрономическая** астрономик труба, телескоп.

**Труба Галилея** Галилей көпшәсе (телескобы) *(объектларны туры хәлдә күрсәтә торган телескоп; кабарынкы һәм батынкы линзалардан тора).*

**Труба Кеплера** Кеплер көпшәсе (телескобы) *(объектларны кире әйләндереп күрсәтә торган гади телескоп; кабарынкы линзалардан тора).*

**Тубан** Тубан *(Аждаһа йолдызлыгындагы α йолдызы).*

**Тукан** *Тукан (йолдызлык исеме).*

**Туманности внегалактические** галактикадан тыш томанлыклар *(безнең Галактикадан читтә күренә торган шундый ук зур йолдыз системалары).*

**Туманности газопылевые** газ-тузан томанлыклары *(якындагы гигант йолдызның яктыртуы аркасында ялтырап күренә торган тузан һәм газ болытлары).*

**Туманности Галактические** Галактика томанлыклары *(безнең Галактика чикләрендә урнашкан томанлыклар).*

**Туманности кольцеобразные** боҗрасыман томанлыклар.

**Туманности диффузные пылевые** чәчелмә (диффуз) тузан томанлыклары *(якындагы гигант йолдызның яктыртуы аркасында ялтырап күренә торган таркау тузан болытлары).*

**Туманности планетарные** планетар томанлыклар *(түгәрәк яки боҗра рәвешендә күренә торган галактик томанлыклар; кагыйдә буларак, планетар томанлыкларның уртасында үзәк йолдызы була).*

**Туманности радиоизлучающие** радионурланышлы томанлык-

лар *(радиодулкыннар таратучы ультраяңа йолдызлардан торган томанлыклар).*

**Туманности светлые** якты томанлыклар.

**Туманности спиральные** спираль томанлыклар *(спираль рәвешендә күренә торган томанлыклар).*

**Туманности темные** караңгы томанлыклар *(яктырмый торган вак кисәкчекләрдән торган томанлыклар).*

**Туманности эллиптические** эллиптик томанлыклар *(эллипс рәвешендә күренә торган томанлыклар).*

**Туманность Андромеды** Андромеда томанлыгы *(Андромеда йолдызлыгында күренә торган, Галактикадан тыш гаять зур йолдыз системасы).*

**Туманность Конская голова** Ат башы томанлыгы *(Киек Каз Юлында караңгы томанлык).*

**Туманность крабовидная** Крабсыман томанлык *(формасы белән крабка охшаган томанлык; Үгезбозау йолдызлыгында күренә).*

**Тяготение всемирное** бөтендөнья тартылышы, гравитация *(галәмдәге барлык җисемнәрнең бер-берсенә тартылу үзлеге).*

## У

**Увеличение трубы** трубаның (телескопның) зурайтуы *(объектларны зурайтып күрсәтә алу сәләте).*

**Угловой диаметр** почмакча диаметр; **к. диаметр угловой.**

**Угломерный инструмент к. инструмент угломерный.**

**Угол фазы** фаза почмагы *(планетадан Җиргә һәм Кояшка таба үткәрелгән турылар арасындагы почмак).*

**„Угольные мешки"** „Күмер каплары" *(Киек Каз Юлында караеп күренә торган галактик томанлыклар).*

**Удивительная Кита к. Дивная Кита** һәм **Мира.**

**Узел восходящий** күтәрелеш чаты, күтәрелгәндәге чат *(планетаның Кояш тирәли хәрәкәтендә көньяк ярымшардан төньяк ярымшарга күчкәндә эклиптика яссылыгын кисеп үткән ноктасы).*

**Узел нисходящий** төшкәндәге чат *(күтәрелеш чатына капма-каршы нокта);* **к. узел восходящий.**

**Уклонение отвеса** асманың авышуы *(гравитацион аномалия).*

**Ультрафиолетовое излучение звезд** йолдызларның ультрамиләүшә нурланышы.

**Умбриэль** Умбриэль *(Уран планетасының иярчене).*

**Универсальный инструмент (альтазимут)** универсаль инструмент *(күк яктырткычларының биеклеген һәм азимутын төгәл үлчәргә мөмкинлек бирә торган астрономик инструмент).*

**Уравнение времени** вакыт тигезләмәсе *(уртача һәм чын Кояш вакытлары арасындагы аерма; Кояш сәгате буенча чын Кояш вакыты табылган булса һәм астрономия календаре буенча вакыт тигезләмәсе билгеле булса, уртача җирле вакытны табып була).*

**Уравнение центра** үзәк тигезләмәсе *(планета хәрәкәтенең чын һәм уртача аномалияләре арасындагы аерма).*

**Уран** Уран *(Кояштан 2870 миллион километр ераклыкта, 7 нче урында әйләнеп йөри торган гигант планета; 5 иярчене бар).*



**Уровень** тигезләгеч *(тигезлек үлчәү-урнаштыру коралы).*

**Ускорение свободного падения** тоткарсыз төшү тизләнеше *(күк җисемнәренең тартуы нәтиҗәсендә әйберләрнең шул җисемгә төшкәндәге тизләнеше).*

**Ускорение силы тяжести** Җир тарту тизләнеше *(җисемнәрнең Җиргә тоткарсыз төшү тизләнеше).*

**Установка параллактическая (экваториальная) к. параллактическая установка.**

## Ф

**Фаза вращения** әйләнү фазасы.

**Фазы затмения** тотылу фазалары *(Ай һәм Кояш тотылганда күзәтелгән төрле каплану фазалары).*

**Фазы Луны** Ай фазалары *(Ай дискындагы якты өлешнең периодик рәвештә үзгәреп торуы).*

**Факелы** факеллар *(Кояш фотосферасының кырыйларында, гадәттә таплар әйләнәсендәге якты урыннар).*

**Факт** Факт *(Күгәрчен йолдызлыгындагы α йолдызы).*

**Феба** Феба *(Сатурн планетасының иярчене).*

**Фекда** Фекда *(Зур Җидегәннең γ йолдызы).*

**Фемида** Фемида *(Сатурн планетасының иярчене).*

**Феникс** Феникс *(йолдызлык исеме).*

**Фетида** Фетида *(Сатурн планетасының иярчене).*

**Фигнерия** Фигнерия *(астероид).*

**Физически-двойные звезды** физик куш йолдызлар; **к. звезды физически-двойные.**

**Флинтглас (флинт)** флинтглас, флинт *(кургаш катнашкан һәм яктылык сындыру сәләте зур булган пыяла сорты, оптик приборларда кулланыла).*

**Флоккулы** флоккуллар *(Кояш хромосферасында факеллардан югарырак булган якты, кызу болытлар).*

**Фобос** Фобос *(Марс планетасының зуррак иярчене).*

**Фокальная плоскость** фокаль яссылык, фокус яссылыгы *(оптик системаның, мәсәлән объективның, төп күчәренә перпендикуляр итеп фокусы аша үткәрелгән яссылык).*

**Фокус главный** төп фокус *(оптик системада төп күчәргә параллель төшкән нурларның күчәрдә кисешү ноктасы).*

**Фокусы** фокуслар *(1. оптик системага параллель төшкән нурларның кисешү нокталары — ике якта икәү; 2. Гипербола, парабола һәм эллипс яссылыгында ята торган махсус нокталар; ул ноктадан алып әлеге кәкре сызыкларның теләсә кайсы ноктасына кадәр булган араның шул ноктадан алып тиңдәш директрисага кадәр булган арага чагыштырмасы бу кәкренең эксцентриситетына тигез).*

**Фомальгаут** Фомальгаут *(Көньяк Балык йолдызлыгының ак төстәге α йолдызы).*

**Фотогелиограф** фотогелиограф; **к. гелиограф.**

**Фотографическая величина к. звездная величина фотографическая.**

**Фотометр клиновой** чөйле фотометр *(күк яктырткычларының йолдызча зурлыгын визуаль юл белән үлчәү өчен хезмәт итә торган прибор; аның төп өлеше яктылыкны йота торган чөй-*

*дән гыйбарәт. Бу чөй ярдәмендә йолдызның яктылыгын ясалма йолдыз зурлыгына кадәр киметергә мөмкин).*

**Фотосфера** фотосфера *(Кояшның 200 километр чамасы калынлыктагы, 4000° чамасы температуралы күзгә күренә торган катлавы).*

**Фраунгоферовы линии** Фраунгофер сызыклары *(спектрда Кояш яктысының Кояш атмосферасында йотылуы аркасында барлыкка килгән сызыклар).*

**Фундаментальные звезды** фундаменталь йолдызлар, төп йолдызлар *(координаталары аеруча төгәл билгеләнгән 1000 нән артык йолдыз).*

## Х

**Хамал** Хәмәл *(Овен йолдызлыгында α йолдызы).*

**Хамелеон** Хамелеон *(йолдызлык исеме).*

**Хромосфера** хромосфера *(Кояш атмосферасының ун мең километрлар калынлыктагы түбәнге якты катлавы).*

**Хранение точного времени** дөрес вакытны саклау *(вакытны системалы рәвештә дөреслэп бару).*

**Хронограф** хронограф *(астрономик сәгать белән тоташтырылган һәм кәгазь тасмага вакыт моментларын үзе яза торган аппарат).*

**Хронометр** хронометр *(аеруча төгәл йөри торган сәгать).*

## Ц

**Цвет звезды** йолдызның төсе.

**Целено** Целено *(Үгезбозау йолдызлыгында 16 нчы йолдыз).*

**Целостат** целостат *(Кояш яктылыгын хәрәкәтсез оптик системага юнәлтә торган ике хәрәкәтчел көзгедән гыйбарәт җайланма).*

**Центавр** Центавр *(йолдызлык исеме).*

**Центр небесной сферы** күк сферасының үзәге *(күзәтүче торган нокта).*

**Центры либрации** либрация үзәкләре *(ике материаль нокта тирәсендәге биш махсус нокта — Лагранж нокталары; бу нокталарның берсенә билгеле бер массалы өченче материаль нокта урнаштырылса, өч нокта да үзара ераклыклар чагыштырмасын даими саклаган хәлдә хәрәкәт итәләр).*

**Церера** Церера *(эре астероид).*

**Цефеиды** цефеидлар *(яктылыгы аз үзгәрә торган пульсацияле куш йолдызлар).*

**Цефей** Цефей *(йолдызлык исеме).*

**Цикл солнечной деятельности** Кояш эшчәнлеге (активлыгы) циклы.

**Цирки** цирклар *(Айда зур диаметрлы түгәрәк тигезлекләр).*

**Циркуль** Циркуль *(йолдызлык исеме).*

**Циферблат** циферблат *(электр сәгате мәгънәсендә).*

## Ч

**Час долготы** (почмакча, географик) озынлык сәгате *(берәмлек).*

**Час звездный** йолдызча сәгать *(йолдызча тәүлекнең $^1/_{24}$ өлеше).*



**Часовая ось** сәгатьләр күчәре; **к. ось полярная (часовая).**

**Часовой круг** сәгатьләр түгәрәге; **к. круг часовой.**

**Часовой угол** сәгатьләр почмагы *(күк яктырткычы аша үтүче авышулар түгәрәге яссылыгы белән меридиан яссылыгы арасындагы ике кырлы почмак).*

**Час солнечный** Кояшча сәгать *(уртача Кояшча тәүлекнең $^1/_{24}$ өлеше).*

**Часы** Сәгать *(йолдызлык исеме).*

**Часы звездные** йолдыз сәгате *(йолдызча тәүлекнең өлешләрен күрсәтә торган прибор — сәгать; ул гадәттәге сәгатькә караганда тизрәк йөри һәм циферблаты 24 өлешкә бүленгән була).*

**Часы солнечные** Кояш сәгате; **к. солнечные часы горизонтальные** һәм **солнечные часы экваториальные.**

**Чаша** Табак *(йолдызлык исеме).*

**Число месяца** айның көне, дата.

## Ш

**Шапки планет (шапки полярные)** планеталарның бүреге, поляр бүрекләр *(кайбер планеталарның, мәсәлән Марсның, котып өлкәләрендә кыш көне су яки башка матдәләр каты хәлгә килүдән хасил була торган кар һәм боз катламы).*

**Шаровые скопления к. скопления шаровые.**

**Шаф** Шаф (Кассиопея **йолдызлыгында** β йолдызы).

**Шеат** Шеат *(Пегас йолдызлыгында β йолдызы).*

**Шедир** Шедир *(Кассиопея йолдызлыгында α йолдызы).*

**Широта гелиографическая** гелиографик киңлек *(Кояш өслегендәге ноктаның Кояш экваторыннан исәпләнгән почмакча ераклыгы).*

**Широта гелиоцентрическая** гелиоцентрик киңлек *(Кояш өстендәге ноктадан Кояш үзәгенә таба үткәрелгән радиус белән Кояш экваторы арасындагы почмак; Кояшның поляр кысылуы булмаганлыктан, гелиоцентрик киңлек гелиографик киңлеккә туры килә).*

**Широта географическая** географик киңлек *(Җир өстендәге урынның географик координаталарыннан берсе; шул урынга төшерелгән асма белән экватор яссылыгы арасындагы почмак).*

**Широта геоцентрическая** геоцентрик киңлек *(Җир өстендәге ноктага Җир үзәгеннән үткәрелгән радиус белән экватор яссылыгы арасындагы почмак; гомумән алганда, ул географик киңлеккә туры килми).*

**Широта светила гелиоцентрическая** яктырткычның гелиоцентрик киңлеге *(Кояштан яктырткычка, мәсәлән берәр йолдызга, таба үткәрелгән туры белән эклиптика яссылыгы арасындагы почмак).*

**Широта северная** төньяк киңлек *(Җир экваторыннан төньяктагы урынның географик киңлеге).*

**Широта селенографическая** селенографик киңлек *(Ай өслегендәге урынның Ай экваторыннан почмакча ераклыгы).*

**Широта южная** көньяк киңлек *(Җир экваторыннан көньяктагы урынның географик киңлеге).*

**Широты средние** урта киңлекләр *(төньяк яки көньяк ярымшарда 23° 27′ белән 66° 33′ лы географик киңлекләр арасындагы өлкәләр).*

## Щ

**Щель Кассини** Кассини ярыгы; **к. деление Кассини.**
**Щит** Калкан *(йолдызлык исеме).*

## Э

**Эвекция** эвекция *(Ай хәрәкәтендәге бозылулардан иң зурысы; бу үзгәрешнең периоды 31,8 тәүлек тәшкил итә).*
**Эволюция звезд** йолдызлар эволюциясе *(йолдызларның килеп чыгышы һәм үсеш-үзгәреш тарихы).*
**Экватор земной** Җир экваторы *(Җирнең үзәге аркылы һәм Җирнең күчәренә перпендикуляр итеп үткәрелгән яссылыкның Җир өслеге белән кисешү сызыгы).*
**Экватор небесный** күк экваторы *(күк сферасы дөнья күчәренә перпендикуляр яссылык белән кисешкәндә барлыкка килгән зур түгәрәк).*
**Экваториал** экваториал; **к. параллактическая установка** һәм **экваториальная установка.**
**Экваториальная установка (экваториал) к. параллактическая установка.**
**Экваториальные координаты** экваториаль координаталар *(авышу һәм туры күтәрелү координаталары);* **к. координаты экваториальные).**
**Экзаменатор уровней (испытатель уровней)** тигезлек сынагыч *(тигезләгечтәге бүлемнең кыйммәтен төгәл билгели торган сизгер җайланма).*
**Экзосфера** экзосфера *(Җир атмосферасының иң тышкы сирәк өлкәсе;* 500—600 *километр биеклектә башланып, берничә мең километрга кадәр сузыла. Анда молекулаларның космик киңлеккә диссипацияләве мөмкин).*
**Эклиптика** эклиптика *(күк сферасында Кояш үзәгенең ел буенча хәрәкәт итә торган зур әйләнәсе).*
**Эксцентриситет эллипса** эллипсның эксцентриситеты *(эллипснең сузынкылыгын характерлый торган зурлык; фокустан үзәккә кадәр булган араның зур күчәргә чагыштырмасына тигез).*
**Электра** Электра *(Үгезбозау йолдызлыгында 17 нче йолдыз).*
**Элементы орбиты** орбита элементлары *(планета орбитасының эклиптика яссылыгына авышлыгы һәм күтәрелеш чатының озынлыгы).*
**Эллипс** эллипс *(фокуслар дип аталган ике ноктадан ераклыклар суммасы даими булган йомык кәкре сызык).*
**Эллипсоид вращения** әйләнү эллипсоиды *(эллипсны кечкенә яки зур күчәре тирәсендә әйләндергәндә барлыкка килә торган өслек).*
**Элонгация восточная** көнчыгыш элонгация; **к. восточная элонгация.**
**Элонгация западная** көнбатыш элонгация; **к. западная элонгация.**



**Энергия Солнца** Кояш энергиясе *(водород гелийга әверелгәндә, ягъни атом-төш реакциясе вакытында барлыкка килә).*
**Энцелад** Энцелад *(Сатурн планетасының иярчене).*
**Эпагомены** эпагоменнар *(Борынгы Мисыр календаренда 360 көнлек ел әйләнәсенә өстәлә торган 5 „артык" көннең исеме).*
**Эпицикл** эпицикл *(Птолемей системасында планета үзәге туры хәрәкәт итә торган кечкенә әйләнә; бу әйләнәнең үзәге зуррак әйләнә — деферент буенча хәрәкәт итә дип алынган).*
**Эра календарная** календарь эрасы *(мәс., яңа эра).*
**Эридан** Эридан *(йолдызлык исеме).*
**Эрот** Эрот *(эре астероид).*
**Этра** Этра *(астероид).*
**Эфемерида** эфемерида *(күк яктырткычларының ел көннәренә карата алдан ук исәпләп куелган координаталарын күрсәткән астрономик таблицалар).*
**Эффект Доплера к. принцип Доплера.**
**Эффект парниковый (оранжерейный)** парник (оранжерея) эффекты *(планета атмосферасында углекислый газ һәм су парлары күп булганда, планета өслегеннән космоска җылылык нурланышы чәчелүнең кимүе аркасында температура күтәрелү).*
**Эффективная температура Солнца** Кояшның эффектив температурасы *(Кояш зурлыгындагы һәм Кояш биргән кадәр энергия тарата ала торган шартлы күк җисеменең температурасы — 6000°).*

## Ю

**Юг (географический)** көньяк, географик көньяк *(чын горизонтның күк меридианы белән кисешкән һәм дөньяның көньяк полюсына якын торган ноктасы).*
**Южная Гидра** Көньяк Гидра *(йолдызлык исеме).*
**Южная Корона** Көньяк Гажы *(йолдызлык исеме).*
**Южная Рыба** Көньяк Балыгы *(йолдызлык исеме).*
**Южный Крест** (**Крест**) Көньяк Хач *(иске карталарда йолдызлык исеме).*
**Южный треугольник** Көньяк Өчпочмагы *(йолдызлык исеме).*
**Южный тропик к. тропик Козерога (тропик южный).**
**Юнона** Юнона *(астероид).*
**Юпитер** Юпитер *(Кояштан уртача 778 млн. км ераклыкта, бишенче урында әйләнеп йөри торган гигант планета;* 12 *иярчене бар).*

## Я

**Явление Доплера** Доплер күренеше; **к. принцип Доплера.**
**Ядро кометы** кометаның төше *(кометаның баш өлешендәге иң тыгыз урын).*
**Япет** Япет *(Сатурн планетасының иярчене).*
**Яркость звезд** йолдызларның яктылык дәрәҗәсе, яктылыгы.
**Яркость неба** күк йөзенең яктылыгы.
**Ясли** Ясле *(йолдыз тупланышы).*
**Ящерица** Кәлтә *(йолдызлык исеме).*

## КАЙБЕР КОНСТАНТАЛАР ТАБЛИЦАСЫ

| | |
|---|---|
| Яктылык тизлеге . . . . . . . . . . . | $2{,}988 \cdot 10^{10}$ *см/сек* |
| Гравитация константасы . . . . . . . | $6{,}67 \cdot 10^{-8}$ *дин см²/г²* |
| Тропик ел . . . . . . . . . . . . . . | 365, 2422 *тәүлек* |
| Сидерик ел . . . . . . . . . . . . . | 365, 2564 *тәүлек* |
| Экваторның эклиптикага авышлыгы . . | 23°27′9″ |
| Эклиптика буенча прецессия . . . . . | бер елга 50″,26 |
| Айның уртача ераклыгы . . . . . . . | $3{,}844 \cdot 10^{10}$ *см* |
| Айның массасы . . . . . . . . . . . | $7{,}35 \cdot 1^{25}$ *г* |
| Айның радиусы . . . . . . . . . . . | $1{,}74 \cdot 10^{8}$ *см* |
| Кояшның массасы . . . . . . . . . . | $1{,}99 \cdot 10^{33}$ *г* |
| Кояшның радиусы . . . . . . . . . . | $6{,}96 \cdot 10^{10}$ *см* |
| 1 астрономик берәмлек . . . . . . . | $1{,}496 \cdot 10^{13}$ *см* |
| 1 яктылык елы . . . . . . . . . . . | $9{,}461 \cdot 10^{17}$ *см* |
| 1 парсек . . . . . . . . . . . . . . | $3{,}086 \cdot 10^{18}$ *см* |
| Галактиканың радиусы . . . . . . . . | 15 000—20 000 *парсек* |
| Галактиканың үзәк өлешендәге калынлыгы . . . . . . . . . . . . . . | 5000 *парсек* |
| Кояшның галактика үзәгеннән ераклыгы . . . . . . . . . . . . . . | 10000 *парсек* |
| Галактиканың үзәктән Кояш ераклыгында әйләнү тизлеге . . . . . . . | 250 *км/сек* |



## ҖИРНЕҢ ГЕОМЕТРИК ҺӘМ ФИЗИК ХАРАКТЕРИСТИКАЛАРЫ

| | |
|---|---|
| Экваториаль радиусы . . . . . . . . | 6378,160 *км* |
| Поляр радиусы . . . . . . . . . . . | 6356,777 *км* |
| Җир эллипсоидының кысылышы . . . | 1 : 298,25 |
| Уртача радиусы . . . . . . . . . . | 6371,032 *км* |
| Мәйданы . . . . . . . . . . . . . . | $510{,}2 \cdot 10^{6}$ *км²* |
| Күләме . . . . . . . . . . . . . . . | $1{,}083 \cdot 10^{12}$ *км³* |
| Массасы . . . . . . . . . . . . . . | $5976 \cdot 10^{21}$ *кг* |
| Уртача тыгызлыгы . . . . . . . . . | 5518 *кг/м³* |
| Авырлык көче тизләнеше | |
| а) экваторда . . . . . . . . . . | 9,78049 *м/сек²* |
| б) полюста . . . . . . . . . . . | 9,83235 *м/сек²* |
| в) стандарт . . . . . . . . . . . | 9,80665 *м/сек²* |

## ПЛАНЕТАЛАР СИСТЕМАСЫ

| Планета | Кояштан уртача ераклыгы (*млн. км*) | Диаметры (Җир диаметры = 1) | Массасы (Җир массасы = 1) | Уртача тыгызлыгы (Җир тыгызлыгы=1) | Авырлык көче тизләнеше (*м/сек*$^2$) | Параболик тизлек (*км/сек*) | Күчәр тирәсендә әйләнү периоды | Экватор яссылыгының орбита яссылыгына авышлыгы | Иярченнәр саны | Уртача орбиталь тизлеге (*км/сек*) | Кояш тирәсендә әйләнү периоды |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Меркурий . . . . . . . . . | 57,9 | 0,38 | 0,054 | 0,99 | 3,46 | 4,17 | 59 *тәүлек* | 0° | 0 | 47,8 | 88 *тәүлек* |
| Венера . . . . . . . . . . . | 108 | 0,97 | 0,81 | 0,88 | 8,43 | 10,78 | 244 *тәүлек* | ? | 0 | 35,0 | 225 *тәүлек* |
| Җир . . . . . . . . . . . . | 150 | 1,00 | 1,00 | 1,0 | 9,81 | 11,19 | 23 *сәг* 56 *мин* | 23,5° | 1 | 29,76 | 1 *ел* |
| Марс . . . . . . . . . . . | 228 | 0,53 | 0,108 | 0,71 | 4,02 | 5,09 | 24 *сәг* 37 *мин* | 25,2° | 2 | 24,11 | 687 *тәүлек* |
| Юпитер . . . . . . . . . . . | 778 | 11,26 | 318,85 | 0,24 | 27,67 | 60,19 | 9 *сәг* 50 *мин* | 3,1° | 12 | 13,05 | 12 *ел* |
| Сатурн . . . . . . . . . . . | 1427 | 9,4 | 95,3 | 0,12 | 12,74 | 36,28 | 10 *сәг* 44 *мин* | 28,7° | 10 | 9,64 | 29,5 *ел* |
| Уран . . . . . . . . . . . | 2870 | 4,2 | 14,58 | 0,20 | 9,58 | 21,32 | 10,4 *сәг* | 98° | 5 | 6,78 | 84 *ел* |
| Нептун . . . . . . . . . . . | 4496 | 3,9 | 17,26 | 0,29 | 11,22 | 23,43 | 15 *сәг* | 29° | 2 | 5,47 | 165 *ел* |
| Плутон . . . . . . . . . . . | 5947 | 0,45? | 0,93? | 9? | ? | ? | ? | ? | ? | 4,74 | 248 *ел* |

## ПЛАНЕТАЛАРНЫҢ ТАБИГЫЙ ИЯРЧЕННӘРЕ

| Планета | Иярчен | Планетадан ераклыгы (*мең км*) | Радиусы (*км*) | Массасы ($\cdot 10^{24}$ *г*) |
|---|---|---|---|---|
| Җир | Ай | 384,4 | 1738 | 73,4 |
| Марс | Фобос | 9,4 | ≈8 | |
| | Деймос | 23,5 | ≈4 | |
| Юпитер | V | 181 | 80 | |
| | I Ио | 421,8 | 1660 | 79 |
| | II Европа | 671,4 | 1440 | 47,8 |
| | III Ганимед | 1071 | 2470 | 153 |
| | IV Каллисто | 1884 | 2340 | 90 |
| | VI | 11500 | 60 | |
| | VII | 11750 | 20 | |
| | X | 11750 | 10 | |
| | XII | 21000 | 10 | |
| | XI | 22500 | 12 | |
| | VIII | 23500 | 20 | |
| | IX | 23700 | 11 | |
| Сатурн | Мимас | 185,7 | 260 | 0,038 |
| | Энцелад | 238,2 | 300 | 0,07 |
| | Тефия | 294,8 | 600 | 0,65 |
| | Диана | 377,7 | 650 | 1,03 |
| | Рея | 527,5 | 900 | 2,3 |
| | Титан | 1223 | 2500 | 137,0 |
| | Гиперион | 1484 | 200 | 0,11 |
| | Япет | 3563 | 600 | 5 |
| | Феба | 12950 | 150 | — |
| Уран | Миранда | 130,1 | — | |
| | Ариэль | 191,8 | 300 | |
| | Умбриэль | 267,3 | 200 | |
| | Титания | 438,7 | 500 | |
| | Оберон | 586,6 | 400 | |
| Нептун | Тритон | 353,6 | 2000 | 150 |
| | Нереида | 6000? | 150 | 0,05 |



## ИҢ ЯКЫН ЙОЛДЫЗЛАР

| Исеме | Ераклыгы (*парсек*) | Исеме | Ераклыгы (*парсек*) |
|---|---|---|---|
| Центаврның иң якын йолдызы | 1,31 | Аккош 61 нче А | 3,42 |
| Центавр α сы А | 1,33 | Аккош 61 нче В | |
| Центавр α сы В | | Процион А | 3,48 |
| Барнард йолдызы | 1,83 | Процион В | |
| Вольф № 359 | 2,34 | Индусның ε йолдызы | 3,50 |
| BD+36°2147 | 2,52 | BD + 59°1915 A | 3,58 |
| Сириус А | 2,66 | BD + 59°1915 B | |
| Сириус В | | BD + 43°44 A | 3,58 |
| Лейтен 726-8 | 2,69 | BD + 43°44 B | |
| Росс № 154 | 2,93 | Китның τ йолдызы | 3,62 |
| Росс № 248 | 3,16 | СД + 36°15693 | 3,65 |
| Эридан ε йолдызы | 3,30 | ВД + 5°1668 | 3,75 |
| Росс № 128 | 3,34 | СД — 39°4192 | 3,90 |
| Лейтен 789-6 | 3,34 | Каптейн йолдызы | 3,99 |

*Махмуд Салихович Галеев*
*Адлер Камилович Тимергалин*

# РУССКО-ТАТАРСКИЙ СЛОВАРЬ АСТРОНОМИЧЕСКИХ ТЕРМИНОВ

**(на татарском языке)**

Редакторы Л. Ш. Галеева
Художество редакторы Э. Е. Сподикова
Техник редакторы З. А. Ибраһимова
Корректорлары И. Х. Уразова, С. В. Абдуллина

Наборга бирелде 16/V-1973 ел. Басарга кул куелды 12/III-1974 ел. Типография кәгазе № 2, $84 \times 108^{1}/_{32}$. ПФ 04028. Якынча басма табагы 3,34. Учет.-изд. табагы 4,36. Тираж 6000. Заказ Д-179. Бәясе 8 тиен.

Татарстан китап нәшрияты, Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство, Казань, ул. Баумана, 19.

ТАССР Министрлар Советының Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре идарәсенең Камил Якуб исемендәге полиграфия комбинаты. Казан, Миславский ур., 9.

1726 210200
80-25.08.08